Әмирлек

Серле гарәп иле белән кызыксынуым кайчан башланганын төгәл генә әйтә алмыйм. Әбием сөйләгән «Мең дә бер кичә» әкиятләрен тыңлаганда ук күңелемдә туды бугай бу якларны күрү теләге. Адәм баласын ризыгы, әчәсе суы йөртә. Ходайга рәхмәт, безнең дә җыясы ризыкларыбызның беразын гына булса да Гарәп Әмирлегенә илтеп куйган.

6 БИТ

Ун әдипкә – ун сорау: Галимҗан Гыйльманов

8-9 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 3.02.2017 | № 11 (5773)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ЭШЧЕ ҺӨНӘРЛӘР ЧЕМПИОНАТЫ: АБУ-ДАБИ ШӘҺӘРЕНӘ КЕМ БАРЫР?

«WORLDSKILLS» КӨНДӘЛЕГЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Бу көннәрдә Казанда эшче һөнәрләр буенча «Worldskills» «Яшь профессионаллар» төбәк чемпионаты бара. Ярышлар Казан ярминкәсендә һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә үтә.

Алисә САБИРОВА

Чемпионатны тамаша кылырга килүчеләр шулкадәр күп иде, хәтта бер павильонга керү өчен, кимендә, ун минут чират торырга туры килде.

Шуны әйтергә кирәк, елдан-ел компетенцияләрнең асылы үзгәрә, сыйфат яхшыра. Повар-кондитер эшен генә алыйк. Әлеге компетенция буенча төбәк эксперты Лариса Трудовая сүзләренчә, хәзер конкурста катнашучылар ризык пешерүгә бөтенләй башка карашта.

– Бездә бит минут саен регламент үзгәреп тора. Шуңа да катнашучыларда, профессионализмнан тыш, иҗади караш булдырырга тырышабыз. Нәрсә пешерергә тиеш икәнен алар бары тик ярыш алдыннан гына белә. Соңыннан да «кара тартма» дигән әйбер тартып чыгарабыз. Анда теләсә нинди ингредиент булырга мөмкин. Менә шуннан соң ярышучылар ни дә булса әзерләргә тиеш, – ди Лариса Трудовая.

Аларның эшләрен 16 хөкемдар күзәтеп бара. Конкурсантлар тәмле итеп пешерүдән тыш, санитар нормаларга туры китереп чиста эшләргә дә тиеш. Шуңа өстәп, ризыкның авырлыгы, дөрес бирелеше, формасы тикшерелә. Бу таләпләргә туры килгән ризыкларны махсус бүлмәдә утырган шеф-поварлар авыз итеп карый.

– Экспертлар бер-берсе белән киңәшергә, сөйләшергә тиеш түгел. Ризык ошамаган очракта да, моны мимика белән күрсәтү дә тыела. Алар конкурсантларны күрми дә. Мин «WorldSkills» хәрәкәтендә 2011 елдан бирле. Бу эшкә гашыйкмын. Төрле шәһәрләр буйлап йөреп, яхшы шеф-поварлар табуы кыен икәнен аңладым. Чемпионат белем бирү оешмаларын да берләштерер, дип уйлыйм. Без дөрес юлда. Үзебез дә, укыган вакытта, балаларны төрле ресторннарга стажировка узарга җибәрәбез. Әмма менә районнарда тәҗрибә уртаклашу җитеп бетми, – диде Лариса Трудовая.

Республика – флористика белгечләре буенча да алдынгы рәтләрдә. Россия буенча ул – 50 иң перспективалы һөнәрләрнең берсе. Биредә биш конкурсант көч сынашты.

– Безнең бер генә проблема – бүгенге көндә Татарстанның бер генә уку йорты да флористлар әзерләми. Биредә ярышырга килгән һәр конкурсант – үз тырышлыгы белән өйрәнгән кешеләр, – диде Халыкара сервис көллияте вәкиле Юлия Серебрякова.

Әмма менә автомобильләрне ремонтлау һәм карау компетенциясе эксперты, яшьләрне әзерлексез, дип күрсенде.

– Кайберәүләр бөтенләй алардан ни сораганнарын да аңламый. Бер-ике көн машинада казынып кына ярышларда катнашып булмый. Берничә ел шөгыльләнергә, кул шомартырга кирәк. Биремнәр жирәбә белән бүленә. Катнашучылар ике сәгать эчендә машинада булган җитешсезлекләрне табарга һәм ремонт ясарга тиеш, – диде Россия эксперты Дмитрий Ефимов.

→ Ахыры 2нче биттә.

ria.ru

Акмаса да тама

Татарстанда уртача пенсия 140 сумга артты

1 февральдән пенсия арту турында газетабызның алдагы саннарында хәбәр иткән идек. «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә Россия Пенсия фондының Татарстан бүлегендә пенсия түләүләрен билгеләү, яңадан исәпләп чыгару һәм оештыру бүлекчәсе җитәкчесе Светлана Гайдук күпләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирде.

Былтыр пенсияләрне чираттагы индексацияләүне бер тапкыр бирелә торган 5000 сум белән алыштырдылар. Бүген әлеге түләүләр 100 процент күләмдә диярлек башкарылган. Аны 1 млн 119 мең 441 кеше алган. Ниндидер сәбәпләр аркасында әлеге 5000 сумны гыйнвар аенда алырга өлгермәгәннәргә ул февраль ае пенсиясенә өстәлеп киләчәк. Индексация ясалганнан соң, 1 февральдән Татарстанда уртача пенсия 12 400 сумны тәшкил итә (февральгә кадәр ул 12 260 сум иде). Кыскасы, пенсия якынча 140 сумга арткан.

Иминият пенсиясе белән беррәттән федераль ташламага ия категориягә ай саен бирелә торган түләүләр (ЕДВ) дә 5,4 процентка артачак. Әлеге түләүләргә кергән социаль хезмәтләр җыелмасына кагылышлы үзгәрешләр дә бар. Билгеле булганча, социаль җыелманы акчалата да алырга мөмкин. Акчага әйләндергәндә, ул хәзер 1048 сум 97 тиенне тәшкил итәчәк. Аның 807, 94 сумы – авыруны дарулар, медицина эшләнмәләре белән тәэмин итү, 124, 99 сумы – шифаханәгә юлламалар алу, 116, 04 сумы дәвалану урынына барганда тимер юл, шәһәрара җәмәгать транспортында бушлай йөрү өчен каралган. Кеше вафатыннан соң җирләү өчен бирелә торган пособиенең суммасы да артты, хәзер ул 5562 сум булды.

> Пенсия өлкәсендәге үзгәрешләр турында борчыган сорауларыгызны **(843)562-50-03, 8(917)851-69-62** телефоны аша юллый аласыз. Газетабызның киләсе саннарында бу теманы тулырак яктыртачакбыз.

Светлана Гайдук пенсияне яшьтән үк кайгыртырга киңәш итте.

– Пенсия ул – яшьлектә эшләгән өчен картлыкта дәүләттән бирелә торган компенсация. Шуңа да бу өлкәдә хәзердән үк игътибарлы булу сорала. Кайбер оешмаларда эшләүчеләргә хезмәт хакы түләнсә дә, пенсия взнослары тотылмый. Бу өлкәдә кагыйдә бозулар булмасын өчен, һәркемгә үз пенсиясенең ничек исәпләнүен Пенсия фондының рәсми сайтында шәхси кабинетыңда карап барырга була, – диде Светлана Гайдук.

Эльвира МОЗАФФАР.

Чиратта – кертемнәре иминиятләштерелмәгән затлар

1 февральгә «Татфондбанк»ның 91,3 процент кертемчесенә – 42 миллион сумнан артык, «ИнтехБанк»ның 94,1 процент клиентына 12 миллиард сум иминиятләштерелгән кертемнәре кайтарылган. Күптән түгел «Булгар Банк» та үз кертемчеләренә банк-партнерлар аша акчаларын түли башлады. Хәзергә 619 клиент 501 миллион сумлык кертемен кайтара алган, дип хәбәр итте икътисад министры Артем Здунов «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

Банклардан зыян күргән, кертемнәре иминиятләштерелгән клиентларны борчыган сораулар акрынлап хәл ителә, ә менә исәп счетларына салынган акчалары 1 миллион 400 меңнән артып киткән затларга нишләргә? Бу өлкәдә дә боз кузгалыр кебек. Республиканың юстиция министры Лариса Глухова әйтүенчә, Министрлар кабинеты карары белән оешкан консультатив төркем бу атнадан нәкъ менә шул категория кешеләр белән эшли башлаячак.

Эшмәкәрләр арасында микрозаймнар бирү программасына ихтыяҗ барлыгы да сизелә. Соңгы мәгълүматлар буенча, 200 миллион сумлык микрозайм тапшырылган. Эшмәкәрләрнең күбесе хәзер әҗәтләрен каплар өчен генә түгел, бизнесларын үстерү, яңа эш башлау өчен дә Татарстанның эшмәкәрләргә ярдәм итү фондына гариза тапшыра. Микрозаймнарны 3 миллион сумга кадәр рәсмиләштерергә мөмкин. Ә менә зуррак суммада акча алырга теләүчеләр банк-партнерларга мөрәҗәгать итә ала. Алар «Татфондбанк», «ИнтехБанк» клиентларына ташламалы шартларда кредитлар бирергә әзер.

> *Торак-коммуналь хезмәтләрен «Татфондбанк»та түләгән кешеләр үзләрен борчыган сораулар белән* ***(843) 231-14-10*** *телефоны буенча шалтыратып киңәшләшә ала.*

Торак-коммуналь хезмәтләрен «Татфондбанк»та түләгән кешеләр киңәш сорап редакциягә еш мөрәҗәгать итә. Баксаң, Татарстан буенча 609 мең исәп счеты аша узган барлыгы 2,8 миллион сумлык түләү тиешле инстанциягә барып ирешмәгән. Нәтиҗәдә, коммуналь хезмәтләр өчен узган айның түләүләре дә өстәлеп килгән. Бу мәсьәлә буенча тикшерү эшләре алып барыла. Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак коммуналь хезмәтләр министрының беренче урынбасары Алексей Фролов бу «бурычларны» түләргә киңәш итте.

– «Татфондбанк»ка карата кертелгән мораторий вакыты тәгәлләнгәннән соң, банкның киләчәге хәл ителгәч, исәп-хисап ясап, артык түләнгән акчаларны кире кайтарырга тиешләр, – диде ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Эшче һөнәрләр чемпионаты: Абу-Даби шәһәренә кем барыр?

→ **Ахыры. Башы 1нче биттә.**

Станокта токарь һәм фрезер белгечлеге буенча сынауларны Чаллы егете Антон Лоскутов үткәрә. Моннан ике ел элек ул үзе дә нәкъ менә шул юлны үтеп, Сан-Паулу шәһәренә кадәр барып җиткән иде. Антон – «WorldSkills» чемпионы. Бүген ул халыкара дәрәҗәдәге эксперт буларак чыгыш ясый.

– Катнашучылар Чаллы, Алабуга, Бөгелмә, Яшел Үзән шәһәрләреннән килде. Алдагы еллар белән чагыштырам да, быелгы конкурсантлар көчлерәк икән, дигән нәтиҗәгә киләм. Хәзер яшьләр үзләре дә кызыксына, миңа да, өйрәт әле, дип, еш мөрәҗәгать итәләр. Баш тартмаска тырышам. Хәзерге вакытта безгә җиһазлар һәм белгечләр җитми. Кайбер төбәкләрдә барысы да бар, ләкин җитәкчеләр әлегә чемпионатның кирәген аңлап бетерми. Бездә, Аллага шөкер, «Тагын нәрсә кирәк?» дип сорап кына торалар. Мин катнашкан вакытта әле андый әйбер юк иде. Бернәрсә дә булмаган чорда без төрле ярышларга йөрдек. Бигрәк тә Мәскәүне яуларга тырыштык. Шунда мине Германиянең бер оешмасы күреп алды. Алар ярдәме белән, Германиядә стажировка үттем. Анда «WorldSkills» хәрәкәте бик таралган, – диде Антон Лоскутов.

Хәзерге вакытта Антон техник университетның Чаллы шәһәрендәге филиалында белем ала. Башкаларны чемпионатка әзерләргә ярдәм итә.

– Алга таба да катнаша ала идем, ләкин минем башкаларга да мөмкинлек бирәсем килде. Россиягә экспертлар да җитми иде. Үзем тупланган белемнәремне башкалар белән уртаклашасым килде. Тормыш шундый кызык икән ул. Кайчандыр мин, программист буласым килә, дип йөрдем. Акча булмау сәбәпле, укырга керә алмадым. Теләмичә генә токарь һөнәрен үзләштердем. Менә бит барысы да ничек яхшы булып чыкты. «WorldSkills» аркасында хәзер дөнья буйлап сәяхәт итәм, – диде Антон Лоскутов.

Төбәк этабын узган конкурсантлар федераль округлар буенча ярышачак. 16-19 майда исә «WorldSkills Russia» илкүләм ярышлары үтә. Иң көчлеләре октябрь аенда Абу-Даби шәһәрендә узачак «WorldSkills International» ярышларына барачак.

Балтач традицияләргә тугры

Механизаторлар слетына бераз алданрак килеп җиттем. Озак көттерми, ветеран механизаторлар, яшь игенчеләр, авылларның алтын баганасы булган ир-егетләр җыйнала башлады. Һәркайсының йөзләренә, атлап баруларына карап, алар үткән тормыш юлын күрергә, аңларга тырышам...

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

30 градус салкында чылбырлы тракторның суык кабинасында урман ташулар, тузанга батып комбайнда эшләү, бер караңгыдан икенчесенә хәтле сука сукалау һәм иртә яздан кырга чыгарга ашкыну, бөртекне җиргә салып уңышны алганчы көтү, өметләнү... Авыл кешесе яңгыр яуса да, җил иссә дә, кояш күренсә дә, иң элек кырдагы иген, болындагы печән, көшелдәге ашлык турында уйлый. Менә шундый уйлар, хезмәтләр белән күпме еллар үткән, тау-тау бөртек җыйналган.

– Безнең төбәктә нефть тә чыкмый, алтын запаслары да юк, иң зур байлыгыбыз – сез – хезмәт сөйгән кешеләр, – дип мөрәҗәгать итте игенчеләргә район башлыгы Рамил Нотфуллин.

Район 2016 елда 2 млрд 201 млн сумлык табыш алган. Шуның 86,1 проценты – терлекчелектән, 12,5 проценты игенчелектән килгән. Узган ел һәр сыердан 6300 литр сөт сауганнар. Сөтчелек буенча Балтач беренчелекне Кукмара белән бүлешә. Игенчелектә исә республика буенча өченче урында. Кара туфраклы районнар белән берәттән, таш өстендә диярлек бу тиклем уңыш ала алганнар икән, моның артындагы хезмәтне бәяләп бетерерлек тә түгел.

Балтач районында эшләүче хуҗалыкларның һәркайсы диярлек үз аягында нык басып тора. Үз эшен белгән, язмышын туган авылы белән бәйләп, халык белән уртак тел табып эшләүче булдыклы җитәкчеләр шактый районда. Әлбәттә, иң-иңнәр арасында бик яхшылар да була.

Районның иң алдынгы хуҗалыгы – «Татарстан»: бер елда 205 млн 430 мең сумлык табыш алганнар. Хуҗалык җитәкчесе Айнур Нотфуллинның район башлыгының улы икәнен белә идем, моңарчы аның белән беркайчан да аралашканым булмады. Гел уйлый торган идем: теләге булса, район башлыгы үз улын Казанда да урынлы җиргә урнаштыра алыр иде. Ә монда күпме җаваплылык, район халкы алдында йөз аклыгын да югалтмаска кирәк. Тантанадан соң Айнур Нотфуллин белән танышырга бардым, уңышларын серен сорадым, егеткә дә үземчә бәя бирәсем килде.

– Безнең уңыш – хуҗалыкта хезмәт куючы барлык кешеләрнең уртак уңышы. Кешедән нәтиҗәле эш сорар өчен, иң элек тиешле хезмәт хакы да түләргә кирәк. Аннан соң инде барлык технологияләрнең үтәлешен сорарга була. Авыл хуҗалыгында эшләүче һәр кеше бик тә кадерле, хөрмәткә, игътибарга лаек. Шуңа күрә һәр кешенең хезмәтен күрергә, бәяләргә тырышабыз. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы кабул иткән карар нигезендә, уку йортын тәмамлагач та авыл хуҗалыгы тармагына эшкә кайткан белгечкә берьюлы 50 мең сум, аннан соң ике ел дәвамында ай саен 5000 сум өстәмә хезмәт хакы түләнә. Безнең хуҗалыкка эшкә килгән бер белгечебез укуын тәмамлагач та эшкә урнашмаган булган. Идарәдә уртак бер фикергә килдек тә, хуҗалык хисабыннан, үзебез ай саен 4000 сум түләп барырга булдык. Быелгы урып-җыюда эшләгән яшь комбайнчыга да, ниндидер стимул булсын дип, өстәмә 10 000 сум премия бирдек, – дип, үзләренең эш алымнары белән уртаклашты хуҗалык җитәкчесе.

Миңа яшь җитәкченең әңгәмәне саннар телендә түгел, нәкъ менә кешеләргә ихтирам белән алып баруы хөрмәт уятты.

Җитәкче кешенең авыл халкы арасында үз кеше була алуы, әлбәттә, бик мөһим. Уртак максатлар, бер үк мәшәкать-куанычлар булганда, уртак тел табарга да җайлы. Шөңшеңәр авыл җирлеге җитәкчесе Раузит Галиевнең хуҗалыгында тугыз баш мөгезле эре терлек кенә бар. Шуларның өчесе – савым сыер, ун баш сарык, бер ат, ишегалды тутырып, кош-корт тоталар. Узган ел 14000 литр сөт тапшырганнар. Күргәзмәгә ул үзләренең хуҗалыкларында җитештерелгән ризыкларны алып килгән, ни генә юк анда. Шөкер, мондый хуҗалыклар районда бик күп. Балтачлылар авыл кешесенә хас булган төп сыйфатны – хезмәт сөючәнлекне югалтмыйча саклап киләләр.

Бензин – төтенгә, ә газ акчага әйләнә

Республикада транспорт чараларын газ ягулыгына көйләү буенча 2023 елга кадәрге чорга исәпләнелгән программа гамәлгә ашырыла.

– Узган ел 834 машинага газ җиһазы урнаштырылды. Аларның 136сы – физик, ә 698е – юридик затларның транспорт чаралары. Быел газ ягулыгында эшләүче машиналар саны 1500гә җитәр дип фаразланыла, – диде республиканың икътисад министрының беренче урынбасары Рөстәм Сибгатуллин.

Двигательне газ ягулыгына көйләү җиңел автомобильләргә – 70-100 мең сумга, йөк машиналарына 200-400 мең сумга төшә. Программа нигезендә, әлеге чыгымнарның 30 проценты каплана. Җиңел автомобильләргә – 27 мең сумга кадәр, кече йөк автомобильләренә («ГАЗель» рәвешендәгеләр) – 48 мең сумга кадәр, автобусларга –111 мең сумга кадәр һәм магистраль йөк машиналарына 147 мең сумга кадәр акча кире кайтарып бирелә. Тракторларын газ ягулыгына көйләүчеләргә 210 мең сумга кадәр ташлама ясала. Займнар да алырга мөмкин. Әле тагын 1,5 мең кубометр газ тутыру өчен «ягулык картасы» бүләк ителә.

Җиңел автомобильләргә, гадәттә, 80-100 литрлы, ә йөк машиналарына 123 литрлы баллоннар урнаштырыла. 80 литрлы баллонга 20 кубометр газ сыя.

– Газның бер кубометры бер литр бензинга тиң. Ләкин газның бер кубометры – 13 сум, бензинныкы 30 сумнан артык, – диде «Газпром газ-мотор ягулыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Казан филиалы директоры Булат Газизуллин.

Газ ике айдан соң ук акчаны янга калдыра башлый, дип, бу фикерне «Компания Шанс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры Денис Савельев та куәтләде.

«Таттехконтроль» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Марат Ярмиев аңлатканча, газ ягулыгына көйләнгән транспорт чараларына карата нинди дә булса чикләүләр, өстәмә авырлыклар юк.

Татарстанда автомобильләргә газ тутыру компрессор станцияләре (АГНКС) Казан, Чаллы, Түбән Кама, Алабуга, Әлмәт, Яшел Үзән, Лениногорск, Азнакай, Бөгелмә, Мамадыш шәһәрләрендә, Буа һәм Алексеевск районнарында, шулай ук Шәмәрдән эшчеләр бистәсендә эшли. Казан, Чаллы, Әлмәт, Нурлат, Зәй шәһәрләрендә станцияләр тагын төзеләчәк.

Рәдиф КАРАГАЙ.

Казанның тугыз мәдәният йортында өлкән яшьтәгеләр өчен «Тормыш яратучы» («Жизнелюб») клублары эшли башлаган иде. Әби-бабайлар анда бииләр, җырлыйлар, фоторәсемгә төшерергә өйрәнәләр, кулланучылар хокуклары һәм башка темаларга лекцияләр тыңлыйлар. Хәзер аларны компьютер белемнәренә дә өйрәтә башлаганнар.

Җырлап яшәргә кирәк

– Ай ярым вакыт эчендә мәдәни чараларда бер меңнән артык пенсионер катнашты. Әлеге клубка йөрергә теләүчеләр шулкадәр күбәйде, сынау тәртибендә билгеләнгән мәдәният учреждениеләрендә урын кысанланды. Яз җиткәч, «Тормыш яратучы» клубларын башка мәдәният сарайларында да оештырып җибәрәчәкбез, – диде шәһәрнең мәдәният идарәсе җитәкчесе Азат Абзалов.

Казанда 14 мәдәният учреждениесе эшли. Левченко бистәсендәге мәдәният йорты төзекләндерелде. Северный, Вознесенское, Тынычлык, Кадыш, Красная Горка һәм Нагорный бистәләрендә яңа клублар төзелде. Быел Ленин исемендәге мәдәният сарае, «Московский», «Чулпан» мәдәният үзәкләре капиталь төзекләндереләчәк. Башкалада 53 муниципаль китапханә гамәлдә. Узган ел 8 миллион сумга китап фонды яңартылган.

– Казанлылар узган ел китапханәләргә 1 миллион 500 мең мәртәбә мөрәҗәгать иткән. Казан китапханәләрен үстерү үзәге оештырылды, ул китапханәләр челтәренең структур бүлекчәсе сыйфатында эшләячәк. Китапханәләрдә хезмәт күрсәтү төрләре арттырылачак, – диде Азат Абзалов.

Казандагы музыка һәм сәнгать мәктәпләрендә хуҗалык хисабындагы төркемнәрдә 2000гә якын бала шөгыльләнә. Әлеге мәктәпләр хуҗалык хисабындагы, ягъни түләүле төркемнәрдә олыларга да музыка һәм сынлы сәнгать серләрен өйрәтәчәк. Зур Кызыл урамындагы 1нче балалар сәнгать мәктәбендә олылар өчен түләүле төркем апрель аенда ачыла.

Казанда 300 мең пенсионер, алар җәмәгать тормышыннан читтә калмасын. «Тормыш яратучы» клублары челтәре сан ягыннан артсын, җанлансын, дип җилкендерде шәһәр мэры Илсур Метшин.

Дамир БӘДРИЕВ.

«Олимпия уеннарын да үткәрә алабыз!»

«Татарстан Россия Спорт министрлыгы рейтингында «Россия төбәге» номинациясендә икенче урын алды. Без бары Мәскәүдән генә калышабыз. Массакүләм спортны популярлаштыру буенча Татарстан – беренче урында. Республикада узган ел 800гә якын спорт чарасы оештырылган, шуларның 27се Россиякүләм һәм халыкара дәрәҗәдәге чаралар». Яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов еллык эш нәтиҗәләре белән таныштыруны шундый фактлардан башлады.

Алисә САБИРОВА

Өч ел эчендә республикада 671 универсаль спорт мәйданчыгы төзелгән. Илнең бер генә төбәге дә мондый саннар белән мактана алмый.

– 2017 елда, спорт инфраструктурасын үстерү максатыннан, 100 универсаль спорт мәйданы, ясалма боз җәелгән 20 хоккей тартмасы, 11 чаңгы базасы булдырылачак. Иң авырткан җиребез – спорт медицинасы дәрәҗәсенең түбән булуы. Бу өлкәдә белгечләргә кытлык бар. Быел әлеге мәсьәләне хәл итәргә кирәк. Максатыбыз – спорт медицинасы үзәге булдыру, – диде Владимир Леонов.

Ни гаҗәп, быел спорт дөньясында булган төп вакыйга – Рио-де-Жанейро шәһәрендә узган Олимпиада турында бер сүз дә әйтмәде министр. Бу җаваплы вазифаны үз өстенә Олимпия уеннары бронза призеры (2012 ел) Василий Мосин алды. Татарстаннан былтыргы уеннардан 13 спортчы катнашкан иде. Ни кызганыч, безнекеләр Олимпия уеннарында бер генә медаль дә яулый алмады.

– Медальләрсез калсак та, безнең чыгышыбыз – киләсе җиңүләргә керткән өлешебез ул. Бу Олимпия уеннары Татарстанның җиде спортчысы өчен тәүге кат булды, – диде Василий Мосин.

Ул бүгенге вазгыятьтә спортчыларга медальләр өчен генә түгел, хезмәт хакы өчен дә көрәшергә туры килгәнен яшермәде.

– Яхшы хезмәт хакы алу өчен, спортчылар ел саен Европа, дөнья дәрәҗәсендәге ярышлардан нинди дә булса медаль яуларга тиеш. Киресенчә булган очракта, хезмәт хаклары 20 меңнән дә артмаячак. Олимпия медальләрен яулаган кешеләр спорт белән профессиональ шөгыльләнә. Алар, озак вакытка гаиләсен калдырып, елына 365 көн үз хыялларына табa баралар. Ә кечкенә хезмәт хакы аларны башка төбәкләр өчен ярышып йөрергә этәрә, бу исә параллель зачет китереп чыгара. Спортка эшкә караган кебек карарга кирәк. Россиянең спорт төбәге буларак, бу проблеманы без беренчеләрдән булып хәл итәргә тиеш, – диде Россиянең спорт мастеры.

Василий Мосин шулай ук физкультура укытучысы белән тренерларның хезмәт хаклары аермасы зур булуына да басым ясады. Укытучыларның акчалары артса да, тренерларныкы әлегә түбән кала. Бу сүзләрне Татарстан Президенты да күтәреп алды. Әлеге проблеманы хәл итүне ул Татарстанның Финанс министрлыгына йөкләде. Президент тәкъдимен зал көчле алкышлар белән хуплады.

Чакырылган мөхтәрәм кунаклар арасында танылган чаңгычы, Россиянең чаңгы ярышлары федерациясе президенты Елена Вяльбе да бар иде. Аның сүзләренчә, соңгы елларда алар Татарстан Президенты белән ике тапкыр гына күрешкәннәр. Ләкин инде беренче очрашудан соң Татарстанда чаңгы спорты күзгә күренеп үсә башлаган.

– Рөстәм Нургалиевич, «Локомотив» стадионын торгызсак, аңа, элеккеге кебек, чаңгычылар әзерләү үзәге исемен кайтарсак яхшы булыр иде, – дип, мәсьәләне «мөгезеннән» тотып алды федерация президенты. – Аның базасында заманча чаңгы-биатлон комплексы булырга тиеш. Моның өчен стадион тирәсендә барлык шартлар да тудырылган: искиткеч ылыслы урман, рельеф бар. Шулай ук Юдино урманы белән Аккош күле тирәсендәге урман-парк территориясен тоташтыру мөмкин. Шулай итеп, 25 чакрымга сузылган бердәм чаңгы маршруты төзергә була.

Президент исә, «Локомотив», Юдино, Аккош күле территориясе этаплап төзекләндерелә, дип белдерде.

– Без аларны үзгәртүгә керештек инде. Дөрес, хәзерге вакытта Зәйдә «Ялта-Зай» дигән искиткеч чаңгы үзәге бар, ләкин барысы да чаңгы шуарга анда бара алмый. Ә Казанда чаңгычылар күп, гади халык та кышкы спортка тартыла, –диде Рөстәм Миңнеханов.

Бүген Казан теләсә кайсы спорт чарасын үткәрергә әзер. Хәтта Олимпия уеннарын да! Коллегия утырышында Рөстәм Миңнеханов шулай диде.

– Универсиададан республикада җитди үзгәрешләр башланды. Гомумән алганда, безнең республикада теләсә нинди чараны оештыра алган, теләсә кайсы мәсьәләне чишә алган команда тупланды. «Казан Олимпия уеннарын кабул итә аламы?» – дип еш сорыйлар. «Әлбәттә, берсүзсез!» –диде Рөстәм Миңнеханов.

Россиянең яңа спорт министры Павел Колобков Татарстанның спорт өлкәсендә булган уңышларын югары бәяләде.

Яхшы эшләүчеләргә – машина белән кино җиһазлары

Быелгы ел мәдәни чараларга аеруча бай булды. Мәдәният министры Айрат Сибагатуллин әнә шуларны искә төшерде.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

Республиканың 4000 дәүләт һәм муниципаль мәдәни оешмаларында 20 мең хезмәткәр эшли. Муниципаль мәдәни оешмалар 2015 ел белән чагыштырганда 9,6 процентка күбрәк акча эшләгән. Мәдәният министры Айрат Сибагатуллин бу хакта еллык нәтиҗәләргә багышланган коллегия утырышында хәбәр итте.

Министр Кино елы буларак шул өлкәгә аеруча игътибар бирелүен әйтеп узды.

– Кинематография үсешенә республикада 140 млн 691 мең сум акча тотылды, шуның 58 млн 672 мең сумы – Татарстанның 12 кинозалын җиһазларга исәпләнгән федераль акчалар. Федераль программа буенча төзелгән биш авыл клубына да кино күрсәтү җиһазлары урнаштырылды. Татарстанның киноучреждениеләр белән тәэмин ителеше – 94,5 процент. Республикада бөтен районнарда диярлек стационар кино күрсәтү урыннары бар. Быел 11 фильм төшерелеп, шуның тугызы дәүләт ярдәме белән башкарылды. «Семейные хлопоты» фильмы коммерция кинотеатрларында прокатка чыкты. Әмма шушы күрсәткечләргә ия булуга карамастан, без уңай прокат тарихы булган төбәкләр исәбенә керә алмыйбыз, – дип сөйләде Айрат Сибагатуллин.

Министр милли кинематография үсешенең уңай булуын һәм бу эшнең 2017 елда да дәвам итәчәген әйтте. Үзебезнең фильмнарны популярлаштыру юнәлешендә дә шактый эшләнүен билгеләп үтте. Яхшы эшләгән районнарга кинојиһазлар белән машиналарны Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин тапшырды. Алар арасында Әтнә, Яшел Үзән, Балык Бистәсе, Чирмешән, Чистай һ. б. районнар бар. Министр әйтүенчә, быел музейларга, театрларга йөрүчеләр саны да арткан.

Мәдәният һәм сәнгать институты ректоры Рифкат Йосыпов, үзенең чыгышында, уку йортын тәмамлаган яшьләрнең туган якларына кайтып эшлисе килмәвенә борчылуын белдерде. Аңа каршы Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин үз фикерен җиткерде:

– Авылда хезмәт хакы аз. Шуңа кайтасылары килми. 20 мең сум хезмәт хакына кемнең эшлисе килсен?

Бу сүзләрдән соң зал гөләп алды, чөнки купләрнең бу акчаны да күргәне юк.

– Аларны туган якларына яисә башка авылларга эшкә кайтару өчен тиешле хезмәт хакы һәм торак кирәк. Муниципаль районнарның хакимиятләре, Мәдәният министрлыгы белән берлектә, авылга эшкә кайтуны алдан сөйләшеп укытырга тиеш. Безнең телебез, гореф-гадәтләребез авылларда гына саклана, – диде ул.

Дәүләт Советы рәисе мәдәният өлкәсендә башта район җирлегендә эшләгән, соңыннан министр урынбасары булган мәрхүм Мөҗип Низамиевны күпләргә үрнәк итеп искә алды.

Соңыннан бер төркем мәдәният хезмәткәрләренә дәүләт бүләкләре тапшырылды. Россия Федерациясенең ЮНЕСКОдагы даими вәкиле Элеонора Митрофанова исә «Дуслык» ордены белән бүләкләнде.

Яңа ел килгәнгә бер айлап вакыт узса да, әле булса бәйрәм тәэсире белән яшибез. Чөнки Яңа елны ел буе көтеп аласың, ә ул көнне авыл мәдәният йортында узган кичә, чыннан да, ел буена сөйләргә җитә. Төрле шәһәрләрдә яшәүче авылдашларыбыз да, анда катнашыр өчен, махсус кайта. Маскарадка һәркем үз куллары белән төрледән-төрле киемнәр тегеп кия. Быел «әтәчләр», «тавыклар» аеруча күп булды.

Сездә ничек, бездә болай

Без, гомумән дә, бик күңелле яшибез. Авыл мәдәният йорты сәхнәсендә урта яшьтәгеләр һәм әле генә пенсиягә чыгучылар Туфан Миңнуллинның «Исәнмесез» дигән әсәрен сәхнәләштерде. Артистлар бик шәп уйнады. Мәдәният йортына тамашаны карарга олысы-кечесе җыелган иде, хәтта күрше Гамурин авылыннан да килделәр. Мондый кичә-концертлар авыл мәдәният йортында еш була. Аларда гадәттә үсмер балалар, «Яшьлек» фольклор ансамбле һәм дә җыр-моң сөйгән авылдашлар катнаша. Хәтта кызыгып китеп, тамашачылар да сәхнәгә менә.

Иҗатка тартылучылар күп. Красноярск краеның Литва диаспорасы оештырган «Милли киемдәге курчак» конкурсында исә мәктәп укучылары, балалар бакчасына йөрүчеләр катнашты. 2нче сыйныф укучысы Әмир Әхмәтовның эше икенче турга Красноярскига җибәрелде һәм ул анда өченче урынга лаек булды. Эшен край китапханәсендә оештырылган күргәзмәгә җибәрделәр.

Динебезне дә онытмыйбыз. Декабрь буе авылдашларым Мәүлид мәҗлесләре уздырды, ял көннәрендә мәчеткә җыелып, Мәүлид кичәләре үткәрдек. Мөнәҗәтләр, салаватлар көйләп укыдык. Әбиләрнең хәтерендә булган мөнәҗәтләрне дәфтәрләргә язып, видеоларга төшереп, киләчәк буыннар өчен саклап калырга тырышабыз. 22 гыйнварда борынгы Енисейск шәһәрендә 1905 елны салынган мәчет реставрациядән соң кабат ачылды. Ул бәйрәмгә дә кунаклар кайлардан гына кайтмады.

Һәдия ҖӘЛӘЛЕТДИНОВА,
Әтнәшкә авылы урта мәктәбенең балалар бакчасы тәрбиячесе.
Красноярск крае,
Казачинск районы.

Кайда да бердәмлек кирәк

Безнең Чистай районы, Татар Ялтаны авылында мәдәни тормышта җанлылык сизелә дип килдем әле бу юлы кунакка кайткач. Шулай булмый ни, Лидия Мияссарова клубта эшен жиң сызганып башлады. Алар авыл китапханәсе мөдире Әлфия Галимова белән Яңа ел бәйрәмен дә зур әзерлек белән, күңелле итеп үткәрделәр.

Интернат-мәктәп коллективының тырышлыгы да зур булды. Китапханәче Әлфия Галимованың җырларын тамашачы һәр бәйрәмдә түземсезлек белән көтеп ала. Шул ук вакытта ул үзе язган юмористик әсәрләрне театральләштереп, сәхнәгә куя. Аның «Китәм булгач китәм!», «Кәҗә мал түгел» дигән юмористик әсәрләрен кат-кат искә алып көләбез. Лидия Мияссарова, Альберт Хисаметдинов, Ләлә Мәзгутова, Раилә Баева, Айгиз һәм Адел Закировлар да чын артистлардан ким түгел. Тамашачы бик яратты үзләрен. Җырчыларыбыз Сания Ситдыйковага, кунакка кайткан авылдашыбыз Рамил Әгълиуллинга да бары рәхмәт сүзләре генә әйтәсе килә. Җырчыларга кытлык юк бездә, тик менә баянчыбыз Рәшит Вәлиәхмәт улының эштән китүе генә бераз көтелмәгәнрәк булды. Ни дисәң дә, өлкән буын гармунга җырларга ярата шул.

Әлфия ГАЛИМОВА,
Түбән Кама.

Кат-кат билет тикшертмәгез!

Беркөнне автобуста яшь кенә кондуктор хатын яныма килде дә юл йөрү билетын валидаторы белән икенче кат тикшерергә сорады. Мин каршы килдем. «Ни өчен икешәр тапкыр тикшерәсез?» – дип сорагач, «План тулмый», – дип куйды.

Алар әйтә дип, башкалар да икешәр мәртәбә билетларын сузарга ашыкмасыннар иде. Моңа кадәр пенсионерларның юл йөрү билетларының бәяләрен күтәргәнче дә күзәтелгән иде бу хәл. Кайсы гына автобуска кермә, билетларны кат-кат тикшерделәр. Пассажирларның «юмартлары» өчәр мәртәбә дә тикшертә иде. Шул чагында, бу бер дә юкка түгелдер, дип уйлап йөргән идем. Шулай булып чыкты да. Күп тә үтмәде, билетларның бәяләрен арттырып куйдылар. Хәзер тагын арттырырга вакытлары җиткән, күрәсең. «Автобуста пенсионерлар гына йөри», – дип, югарыдагыларга хисап тотарга җыеналар, ахрысы.

Рәисә ФӘЙЗУЛЛИНА,
Казан.

yimg.com

Балалар китап укымый дигән булабыз

Шәһәребезне бизәп торган Камал театрына татарча спектакльләр карар өчен генә түгел, яңа китаплар белән танышырга да барам. Бик ошаганнарын алып та кайтам. Бер генә баруымда да китапсыз кайтканым юк.

Элек без бала чакта укырга китап юк иде. Яңа китап кайтса, бер атна эчендә укый-укый тетелеп бетә иде. Ә хәзер бик кызык, дөресрәге, кызганыч. Китап күп – укучы юк. Менә күптән түгел генә тагын Камалга бардым. Шунда бер малай белән анага игътибар иттем. Алты яшьләр чамасындагы малай күз явын алырлык балалар китапларының әле берсен, әле икенчесен кулына тотып-тотып карый. Ә анисе аны бу матур китаплар куелган өстәл янынан ничек булса да тизрәк алып китәргә тырыша. Малай аның саен китапларга тартыла. Соңыннан барыбер әни кеше җиңде – баланы буфетка алып китте. Эх, мин әйтәм, балаң китап белән кызыксынганда, алып тоттырырга бит инде шуны. Акча кызганып торасы түгел иде. Берничә елдан ул китап ягына таба борылып та карамаса нишләрсең? Үзебез һаман балалар китап яратмый, укымый дигән булабыз... Яраталар!

Гөлсем ӘХМӘТҖАНОВА,
лаеклы ялдагы укытучы.
Казан.

«Киләчәк йолдызлары»

Сәләтсез балалар булмый, диләр. Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында «Киләчәк йолдызлары» дип исемләнгән концертны караганнан соң моңа тагын бер кат инандым.

Биредә төрле милләтнең талантлы, музыкага гашыйк балалары, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, дирижер Рөстәм Абязов җитәкчелегендәге La Primavera, Казан камера оркестры белән берлектә, төрле уен коралларында уйнады. Нинди генә классик әсәрләр яңгырамады: Бах, Моцарт, Рахманинов, Чайковский, Җиһанов, Сәйдәшев, Ключарев, Мозаффаров, Яхин... Һәрберсен Казан музыка мәктәбендә укучылар баян, скрипка, фортепиано, флейта, аккордеон һәм башка уен коралларында бик оста итеп башкардылар. Мәрьям Гарифҗанова, Җәлил Хәмитов, Азат Җәләлиев, Альберт Гайсаров, Эльмира Мөхәммәтҗанова, Камил Фатыйхов, Камилә Закирова, Гомәр Бикбаев, Ләйсән Нургатина, Наил Галиев, Диләрә Галимованың, 16нчы балалар музыка-сәнгать мәктәбендә оешкан «Нәүрүз» хорының чыгышлары әле дә колагымда яңгырый. Милли киемнәрдән сәхнәгә чыккан алты яшьлек Җәмилә Асадуллинаны зал аеруча алкышларга күмде.

Бу балаларны зур сәхнәләргә алып чыгу өчен җитәкчеләренә, укытучыларына никадәр тырышлык сарыф итәргә кирәк булгандыр. Татарстанның атказанган артисты Лилия Аппакова исә кичәне бик җанлы, мәгънәле итеп алып барды. Әлеге чара инде өченче ел уздырыла икән. Дәвамлы булсын иде ул.

Равилә МӨБАРӘКШИНА,
Казан.

Серле гарәп иле белән кызыксынуым кайчан башланганын төгәл генә әйтә алмыйм. Әбием сөйләгән «Мең дә бер кичә» әкиятләрен тыңлаганда ук күңелемдә туды бугай бу якларны күрү теләге. Адәм баласын ризыгы, әчәсе суы йөртә. Ходайга рәхмәт, безнең дә җыясы ризыкларыбызның беразын гына булса да Гарәп Әмирлегенә илтеп куйган.

ӘМИРЛЕК

ХЫЯЛЫЙ ЧЫНБАРЛЫК

Самолетка утырып, карлы салкын Казаннан күтәрелдек. Дүрт сәгать ярымнан безне бөркү Дубай төне каршы алды. Иртәгесен кунакханәдән чыгып карасам, үз күзләремә үзем ышанмый торам, урамнарда ямь-яшел пальма агачлары. Бөтен нәрсә тузанга баткан. Монда яңгыр бик сирәк – елына ике-өч тапкыр гына ява икән. Чүл уртасына урнашкан шәһәргә килүебезне шунда гына аңлап алдым. Өйләгә таба кояш тагын да ныграк кыздыра башлады. Һава температурасы 31 градуска кадәр җитте. Декабрь аенда бит ул. Ходайның барлыгына, берлегенә тагын да ныграк инана башларлык. Диңгезгә киттек. Декабрь кояшында рәхәтләнеп кызынып, Фарсы култыгында коенып кайттык. Суы җылы, рәхәт. Өнемме бу, төшемме дигәндәй, тагын бер тапкыр телефонымның календарена карап куям: «5 декабрь, 2016 ел».

Еш кына шулай була: хыял белән чынбарлык һич кенә дә тәңгәл килми. Әй кыен була да инде шул чакта. Ләкин Дубайда андый хис кичермәдек. Кай ягына гына карасаң да – күктерәү йортлар. Үзеңне фантастик фильм герое итеп сизә башлыйсың. Ә инде Гиннесслар китабына дөньяның иң биек бинасы булып кергән 828 метрлы, 162 катлы Бурдж Халифә янында үземне чүлдәге ком бөртеге итеп тойдым. Аннары, ул бинаны биеклеккә кеше акылы күтәргән бит, дип тынычландым. Аны боз кушылган махсус измә ярдәмендә төнлә генә төзегәннәр. 2004 елда салына башлап, 2010 елның гыйнварында ачылган бу гаҗәп бина, төзелеп беткәнче үк инде (2007 елда), дөньяда иң биек бина дип табылган.

Дубайның җырлап биюче фонтаннары гына да ни тора! Кичке җидедән ярты сәгать саен үзләренең чыгышын карарга дөньяның бар илләреннән килгән туристлар алдында шулай тантана итә су агымы.

«ҖӘННӘТТӘ ТҮГЕЛМЕ БЕЗ?»

Дубайга барганчы ук маршрутны сызып, ниләр караячагыбызны планлаштырып куйдык. Алар арасында Чәчәкләр паркы да бар иде. Җәй көне монда 50 градустан артык эссе һәм коры булганга, әлеге парк шул кыш айларында гына ачыла икән. Аның матурлыгыннан күзләр камаша. Бездә дә уңган хуҗабикәләр бакчаларында үстерә торган петуньяның нинди генә төсләре юк. Чәчәк түтәлләренең тавис кошы, сәгать һәм хәтта самолет рәвешендәгесе дә бар. Утлар кабынгач, бу гүзәллек тәмам әкияти тылсымлыга әйләнә. Арыган аякларыңны ял иттерәсең килсә, рәхим ит, утыр – йомшак түшәкләр дә әзер. Теләсәң, ятып та тора аласың. Гөлләр арасында ял итеп утыра идек, моңлы азан тавышы яңгырады. «Без җәннәттә түгелме ул?!» – дип, ирем Сирин белән бер-беребезгә карашып куйдык.

Дубайның туристларны үзенә тартып тора торган тагын бер урыны – Глобал Виллидж (Зур авыл). Авыл дисәң дә, дөньяның бөтен илләрен диярлек үзенә җыйган бер олы ярминкә ул. Шушыннан беркая да китмичә генә дә Һиндстандагы «Таҗ Махал»ны, Франциядәге «Эйфель» манарасын һәм дөньяның тагын бик күп могҗизаларын күрергә була монда. Хәтта Мәскәү «Кремлен» дә. Аның капкасыннан кереп, башкорт балы белән чәй дә эчеп чыктык. «Япония»дә, «Кытай»да да булдык. Сугыш барган «Сүрия»нең дә хәлен белештек. Монда кеше бик кызык хисләр кичерә икән. Үзеңне дөнья кендеге итеп тоя башлыйсың.

ЧЫН ЧҮЛГӘ СӘФӘР

Чүлнең төп сыйфаты – сусызлык. Бәлкем шуңадыр, Дубайда йөргәндә, аның чүл уртасындагы шәһәр икәнен уйлап та карамыйсың. Чөнки монда почмак саен фонтаннар, кибетләрендә хәтта шарлавыкларга, акулалар һәм башка океан балыклары яши торган олы аквариумнарга кадәр бар. Чын чүлне күрәсе килә инде үзе. Безгә чүлгә сәфәр тәкъдим иткәч, иң беренче элек монда булган бер танышымның: «Уф, үлә яздым, әҗәлем шул дип торам...» – дигән сүзләре исемә төште. Каршы килергә уйлаган идем дә, иремә машина җене кагылган, барасы килә. Кунакханә ишек төбеннән җип килеп алды. Без кереп утырганда, анда индус гаиләсе бар иде инде. Шәһәрне чыгып озак бармадык, юлның кырыенда сап-сары ком басуы күренде, кәкре-бөкре үскән саксаул куаклары аның чүл икәнен исбатлап тора иде. Тагын бераз баргач, без чын чүлгә җиттек, икенче махсус машинага күчеп утырдык, ком өемнәре – барханнар өстеннән сәяхәтебезне дәвам иттек. Куркыныч килгәндә, һәркем бер төрле чыелдый икән. Рәхәтләнделәр индуслар кычкырып. Ә юл, чынлап та, куркыныч. Биек ком тауларыннан выжылдап менеп китәсең дә иң текә җиреннән аска очасың. Ярый әле килеп җиткәнбез икән. Туктадык. Монда безне дөяләр көтеп тора иде. Акча түләсәң (анда дирхәм дигән берәмлек. 1 дирхәм 17 сумнар чамасы), чиратсыз гына озаклап йөри аласың дөядә. Без дә утырдык. Әй кызгандым да инде хайванны. Өстенә адәм баласы менә алсын өчен, башта ул ал аякларын чүгә, аннары арткыларын. Мескенең тез башлары сөялләнеп каткан. Һәр 5-10 минут саен шул бер үк хәрәкәтләрне башкарып түеп беткәндер инде ул.

БАРЫСЫ ДА КЕШЕ ӨЧЕН

Кунак аз торыр, күп күрер дигәндәй, безне дә бер атна эчендә гаҗәпләндергән, сокландырган әйберләр шактый булды. Шуларның берсе – метро. 75 чакрымга шәһәрнең буеннан-буена сузылган ул. 2009 елның 9 сентябрендә 9 сәгать 9 минут 9 секундта ачылган. Әмирлектә шулай дөньяны шаккатырырга, саннар белән уйнарга яраталар икән. Әлеге метродагы вагоннар йөртүчесез эшли. Юлның күп өлеше җирнең астыннан түгел, өстеннән узганга, вагоннарга утырып, рәхәтләнеп, шәһәрнең матурлыгына сокланып бара аласың. Метрода чисталык, тәртип. Балалы хатын-кызлар аерым ишектән керә. Бу илдә аналарга һәм балаларга мөнәсәбәт әйбәт икәнне аэропортта ук сизгән идек инде. Кечкенә балалары булган гаиләләрне чик аша чиратсыз гына чыгардылар. Метрода да шундый ук мөнәсәбәт. Байлар өчен дә аерым алтын вагоннар бар. Анда башлыча озын ак күлмәкле, чалмалы (мин аларны шәехләр дип атадым) ир-атлар йөри. Кулларында – тәсбих. Тагын шунысына игътибар иттек: беркем беркая ашыкмый. Бездә генә ул бер-беребезне этешә-төртешә чапкан булабыз. Ә болар кабаланмасалар да, калышмаганнар дөньядан. Дубайда һәр кешегә сигез җиңел машина туры килә, диделәр. Анысына бик исем китмәде. Берьюлы сигезендә дә йөреп булмый бит аның. Берсе тәзек булып, кирәк җиреңә алып барып кайтса, шул җиткән. Илләрен яратулары, патриотик тәрбиянең көчле булуы да сизелеп тора. Моңа Төркиядә бер шаккаткан идем инде. Анда ил байрагын бала арбасына да элеп куйганнар. Монда да шуннан ким түгел.

Урамнарда тыныч. Полиция, юл хәрәкәте иминлеге хезмәткәрләре дә бик сирәк күренә. Кеше дә бик күп димәс идем, шул безнең кебек туристлар гына инде. Эссе булгач, кондиционерлы йортларыннан чыкмыйлар бугай. Кунакханә бүлмәләрендә дә кондиционер: җиләс, хәтта бераз салкынча. Метрода да шулай. Җылынырга урамга чыгасың. «Дубай мал»га (мал – кибет дигәнне аңлата) кереп җиткәнче, шәһәрнең матурлыгын әйләнеп-әйләнеп карый аласың. Җитмәсә, атлап торасы да юк, эскалатор үзе алып бара. Карап сокланырга өлгерсәң, шул җитә. Дубайда карлы кыш бөтенләй юк. Ләкин ил халкы кар бәрешеп уйнау рәхәтеннән мәхрүм калмасын өчен, «Эмират мал» дигән икенче бик зур бер кибеттә тау чаңгылары комплексы ачканнар. Хәтта канатлы юлы да бар.

ЧИТ ИЛЛӘРГӘ ЧЫКСАҢ, ОЗАК ТОРМА

Гыйбрәт алыр өчен чык икән, дип бик дөрес әйтелгән. Без дә хыялдагы бу илдә бер атнадан артык тормадык. Бер илдә дә бер атнадан артык торганыбыз юк. Нинди генә рәхәт булса да, өйгә кайтасы килә башлый. Ел әйләнсе җәйләре дә, диңгезләре-комнары да үзләренә булсын! Ничек кенә матур булмасын, ул безнеке түгел.

Казанда, самолеттан төшүгә, безне чын кыш каршы алды. Аяк баскан саен ак карның шыгырдавы ук күңелгә шигырь булып языла. Үпкәләргә салкын саф һава тулгач, рәхәт булып китте. Менә монысы безнеке инде, ү-зе-без- не-ке!

Йолдыз ШӘРАПОВА.

«Иң зур бүләк бер кисәк ипи булды»

«Гомернең яшьлеге гаҗәеп матур. Яшьлектә һаман алга омтыласың, хыяллар артыннан чабасың. Олыгая төшеп, егәрең кими башлагач, үткән тормышыңны искә аласың, узган юлларыңа борылып карыйсың да уйга чумасың...» Рафаэль Ишморатов белән очрашкач та, без аның әнисе – әлеге юлларны язып калдырган Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Рәшидә Җиһаншина турындагы хатирәләрне яңарттык.

Рәшидә Җиһаншина

Рафаэль Ишморатов

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

– Рафаэль абый, әниегез заманында ил белән идарә итүче Екатерина патшабикә ролен дә, дөньяны авызлыклый алмавына чыдый алмый йөрүче Клеопатра ролендә дә уйнаган артист. Үзе дә театрда узган 60 елның 12сен директор булып эшләгән кеше. Сәхнәдә һәм тормышта бу рольләрне, вазифаны башкару өчен бераз кырыслык та кирәк булгандыр. Гаиләдә дә сизелә идеме ул кырыслык?

– Кирәк чакта, өйдә әни бик кырыс та була белде. Үзебездә яман гадәтләр булдырмаска әни ярдәм итте. Без тәмәке белән шаярырга да әнидән курка идек. Бервакыт ишегалдында карта уйнап утырабыз. Арада «жулик» дип йөртелгән малайлар да бар. (Мин аларның барысын да ота торган идем.) Әни безнең карта уйнаганны күреп алган да каеш тотып чыккан. Шунда барыбызга да каеш эләкте. Шул чакта берсе дә аңа сүз әйтмичә, таралышып бетте. Шул ук вакытта мәрхәмәтле дә иде әниебез. Үзебезнең яисә янәшә йортта яшәүче мохтаҗ балаларга да ярдәм итте ул. Соңыннан аларның кайберләренә эшкә дә урнашырга булышты.

– Сугыш афәте сезнең гаиләне дә читләтеп үтмәгән. Әтиегез язучы Риза Ишморатны яу кырына озаткач, Рәшидә апага ике бала белән калу җиңел булмагандыр.

– Сугыш вакытында безнең фатирда Украинадан эвакуацияләнеп килгән гаилә яшәде. Йортыбыз мич ягып җылытыла. Аның җылысы җитәрлек булмый. Әнинең кичләр буе, шул мич каршына басып, рольләр ятлавы бүгенгедәй күз алдында. Ул русчадан татарчага фильмнар тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнде. Без бәләкәй чакта аның ничек эшләгәнен күреп үстек. Аннары икебез дә әни янында театрда еш була идек. Бервакыт әни спектакль уйнаганда, мин энем Рөстәмне сәхнә артында карап торырга тиеш идем. Ул ничектер кулымнан ычкынып китте дә, сәхнәгә чыгып, әнинең итәгенә барып ябышты. Ярый әле пәрдәне тизрәк ябып куйдылар.

– Әниегез сезне нинди бүләкләр белән сөендерергә яратты?

– Базардан тәмле ризыклар да алып кайткалый иде. Әмма безнең өчен иң зур бүләк бер кисәк ипи булды.

– Канатларны каера ул аерылу газаплары, диләр бит. Әти-әниегезнең аерылышуын сез ничек кичердегез?

– Әтинең сугышта чакта бер хатын белән яшәгәнлеген белгәч, әни аерылышырга булды. Без, билгеле инде, моны авыр кичердек. Әмма алар сөйләшкәнчә, мин әти янында яши башладым. Әни янына барып йөрдем. Ул Илдар исемле кешегә кияүгә чыкты. Аның да үз кызы ияреп килде. Әмма Илдар абый авырып үлеп китте. Мине үз өебез ныграк тартты, шуңа күрә әни янына кире кайттым. Әти язучы Рәисә Ишморатовага өйләнде. Аларның улы Фәрит – Дания Нуруллинаның ире иде. Ләкин ул кыска гомерле булды. Без барыбызның да туган көннәрен әтинең гаиләсе белән бергә үткәрә идек. Әти белән әни бер-берсенә үч сакламады.

– Рәшидә апа Югары Совет депутаты буларак та кешеләргә ярдәм иткән. Пенсиягә чыккач та, өйдә тик кенә утырмаган.

– Ул «Инсаният» труппасы оештырып, өлкән артистлар белән спектакльләр куйды. Мохтаҗларга ярдәм итте. Пьесаларын да өлкәннәр өчен махсус үзе язды. Биш китабы дөнья күрде.

– Иҗат белән шөгыльләнү берәрегезгә күчмәдеме?

– Рөстәмдә бар андый сәләт. Бәләкәй чагында беренче мәртәбә «Кыстыбый, өчпочмак һәм пәрәмәч» дигән әкият язып әнигә күрсәткәч, ул аңа ошаган иде. Шунда: «Молодец, кыймылдарга кирәк», – дип куйган иде. Ул хәзер дә журналларга язып тора.

– Улыгыз Айратның сәнгать юлыннан китүенә Рәшидә апа бик сөенгән иде.

– Әйе, ул аңа аеруча игътибарлы булды. Айрат музыка белән шөгыльләнә башлагач, аңа кларнет алырга акча бирде. Ул аны Париждан алып кайтты. Аннан соң әни Айратны театрның оркестрына да урнаштырган иде. Әмма ул чит илгә китеп барды. Сеңлесе Суфиянның кызы Юлия Җиһаншинаның да сәхнә кешесе булуына һәм үзенең фамилиясен дәвам итүенә куанды әни.

– Рәшидә апаның йөрәге соңгы көннәренә кадәр «театр» дип типкәнен беләбез.

– Гомеренең соңында ул үзен театрга алып баруыбызны үтенде. Әмма аңа керергә хәле юк иде инде. Машина белән театр тирәли әйләндерергә кушты. Шунда озак кына театрга карап торды. Бу аның яраткан театры белән хушлашуы иде.

– Быел Рәшидә Җиһаншинаның тууына 100 ел тулу билгеләп үтеләчәк. Ул чара алдыннан үзегездә нинди планнар бар?

– Иң элек әнинең кабер ташын яңартырга исәпләп торабыз. Аннары әни турында берәр документаль фильм төшерелсә, бик әйбәт булыр иде...

ТОРМЫШ КЫЙПЫЛЧЫКЛАРЫ

Замана зәхмәте

Замана алга бара, фән-техника казанышлары арта, тормыш нык кызулады хәзер. Кичәге яңалык бүген инде гадәти хәл, бүген санаган акча иртәгәгә җитми. Халык кинәт кенә байлар һәм ярлыларга бүленде. Чын-чынлап яшәргә вакыт җитми, акча саныйбыз, керем эзлибез, алданудан куркабыз. Нәтиҗәсе – күз алдында. Үз-үзенә кул салучылар саны буенча Россия дөнья буенча иң алдынгы урыннарны били, психик авырулар саны көннән-көн үрчи, гаиләләр таркала. Урамда йөргән халыкка күз саласың – бар да борчулы кыяфәтле, кая-дыр ашыга, юк кына сәбәптән дә котырып китәргә әзер. Өлкәннәр: «Элек тә эчә идек, ну запойга китүчеләр бик сирәк иде, әллә хәзерге аракыга берәр нәрсә өстиләрме соң?» – ди. Төрле авырулар күбәйде – адым саен яман шеш, шикәр чире, ирләрдә җенси көчсезлек. Нишлисең, табигатьнең законы шундый – һәр нәрсә өчен түләргә кирәк. Табиблар бүгенгә яшәү рәвешенең стрессларга китерүен, стрессның исә депрессиягә, ә анысының шул ук – тән авыруларына һәм эчкечелеккә китерүен искәртәләр. Бездә шулай бит: күрше яңа машина һәм хатынына яңа тун ала. «Син гомергә җебегән инде, әнә күршегә кара», – дип, хатыны ирен сүгә. Аптыраган һәм күршесе кадәр урлый алмаган ир эчә башлый, ә күршесенең яңа тунына кызыккан хатында депрессия башлана – бераздан берсе – эчкече, ә икенчесе – авыру... Бетте гаилә, таркалды тормыш. Хатыны ирен озаграк һәм катырак «игәүләсә», ир әле үзенә кул салырга да мөмкин. Шул стресс һәм депрессиядән котылу өчен, кешеләр дару эчә, уколлар кадата, дәвалана, ә ул дәвалар һәм дарулар организмның башка җиренә китереп суга.

Элек рәхәт иде – бар да бертигез, тигез булмаганнар төрмәдә утыра, стресска сәбәп юк, күрше – күршегә дус, иптәш һәм туган... Нишлисең, кешегә матур яшәргә, тәмле ашарга, затлы киенергә омтылу хас. Ләкин бу омтылыш безне чын, кешечә, табигать кушканча яшәүдән мәхрүм итмиме икән?

Илфак ШИҺАПОВ.

Хушлашу

Тамашачы күңеленә үзенең тальян моңнары белән кереп калган Татарстанның халык артисты Тимер Зиннуровны (Тимергали) соңгы юлга озаттылар. Үзенең 40 ел гомерен театрга багышлаган артистның хезмәт юлы Курчак театрында башлана. Тинчурин театрына килгәннән соң ул башкарган рольләрне санап бетерерлек түгел. «Сынган беләзек»тә – Зиннур, «Әниемнең ак күлмәге»ндә – Максуд, «Гашыйклар тавы»нда – Сәет һәм башка бер-берсенә охшамаган образлары белән истә калыр ул. Аның бүген дә «Алтын көз» спектаклендә уйный торган роле калды. Хезмәттәшләре аны бары тик яхшылыклар белән искә ала.

Исламия МӘХМҮТОВА:

– Тимер ул шаян да, наян да, күңелләрне күтәрә торган кеше иде. Олыларга да, кечеләргә дә игътибарлы булды. Әле 21 гыйнварда гына безгә кереп: «Хәлилне сагынам, кая гармунын бир, уйныйм әле», – дигән иде. Тимер безнең гаилә дустыбыз булды.

Әнәс ГАЛИУЛЛИН:

– Ул театрга бик кирәкле артист иде. Әнә аяк очында гомер буе сыздырып уйнаган тальяны тора. Тимер «алтын куллы» кеше булды. Аның үзе төзи башлаган йорты калды.

Люция ГАЛЛӘМОВА:

– Без озак еллар бергә уйнадык. Тиздән узачак юбилеемда да аның белән партнерлар булып уйнарга тиеш идек. Бу минем өчен аеруча зур фаҗига. Ул бик ярдәмчел кеше булды. Нинди генә ситуациядә калсаң да, аңа таянырга мөмкин иде.

...Сәхнәдәшләре, тамашачылары күңелендә ул озак сакланыр. Мәрхүм Тимер Зиннуровның җәсаден үзенең туган авылы – Лаеш районындагы Пәрәү авылына җирләделәр.

Ун әдипкә – ун сорау: Галимҗан Гыйльманов

1

– Бүгенге әдәбият торышын ничек бәялисез? Кайберәүләр, укырлык әсәр юк бүген татар әдәбиятында, дип зарланырга ярата. Сезнеңчә ничек?

– Мин күтәрелештә, үсештә дип саныйм. Ниндидер яңа этапка керә бара. Ниндидер яңа сулыш көтелә. Яңа буын «ишек кага»…

90нчы еллар ахырыннан, 2000 еллар башыннан ук яңача яза башлаган татар язучыларының активлыгы һич кенә дә кимемәү, аларга Халисә Ширмән, Рөстәм Галиуллин кебек үзенчәлекле каләм ияләренең өстәлүе, шул ук елларда баш калкыткан, хәзер инде татар әдәбиятында саллы шигъри буын буларак формалашып-оешып җиткән шагыйрьләрнең (Ленар Шәехтән башлап Рүзәл Мөхәммәтшинга кадәр булган 20ләп талант иясе хакында әйтүем) шигъри мәйданны ныграк яулый баруы, драматургиядә Илгиз Зәйнигә ияреп сәхнәгә чыгарга омтылган талантлы яшьләр төркеме оешу, яшьләр матбугатында публицистиканың көчәя баруы, гомумән, милли матбугатның әдәби процесска күбрәк игътибар бирә башлавы – болар барысы да шуның ачык дәлиле.

«Укырлык әсәр юк», – дип оран салучылар – елына бер китап та, бер әсәр дә укымаучы кызганыч бәндәләр. Чынлыкта, бүгенге татар әдәбиятында төрле караштагы, төрле фикердә, төрле зәвыкта булган һәркем өчен «ризык» бар. Укучыларым белән еш очрашып торган кеше буларак, мин боларны белеп әйтәм. Үткәннән үк тамырланып килгән традицион татар прозасын, шигъриятен укучы өлкән буын әле дә исән, заманча дөньяви әдәбиятка тартылган яшьрәк буыннар да үсеп җитте, хәтта компьютер технологиясе белән иҗат ителгән экспериментал әсәрләрне егылып укый торган милләттәшләребез дә җитәрлек. Бүген бигрәк тә модернистик, метафизик, хәтта хыялый-мифологик әдәбиятны сораучылар күбәйде. Мин моны шушы иҗат юнәлешендә эшләүче язучы буларак бик яхшы беләм.

2

– Заман белән бергә язучы да, аның җәмгыятьтә тоткан урыны да үзгәрә. Бүген язучы нинди булырга тиеш дип уйлыйсыз, аның миссиясе нәрсәдән тора?

– Заман белән бергә язучы да үзгәрә, әмма аның тоткан урыны үзгәрми, дип уйлыйм. Язучы, әдип, һәрвакыттагыча, милли вазгыятьнең алгы сафында булырга тиеш. Чын язучының миссиясе тотрыклы – ул халыкның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндереп, зәвыгын тәрбияләп, аның мәнфәгатьләрен кайгыртып, актив тормышта яшәргә тиеш. Татарның социальләшүендә, мәдәниләшүендә, хәтта аның үзаңы, иҗтимагый фикере формалашуда язучы хәлиткеч роль уйнарга тиеш. Татарның «милли кемлеген» («национальная идентичность») билгеләү дә, нигездә, сәнгать һәм әдәбият әһелләре карамагында. Без әдипләр, моны ныклап күңелгә беркетеп, иҗади максатларыбыз белән килештереп, бөтен рухыбызны җигеп, җан көчебезне биреп яшәргә, эшләргә тиеш. Халыкның иң алдынгы вәкиле булган китап укучы күңеленә, әлбәттә инде, иң элек әдәби әсәрләребез белән барып ирешәбез. Монысы – төп эшебез, дөресрәге, хезмәтебез. Бу гына аз. Матбугатта саллы фикерләребез, чакыруларыбыз, хәтта набатларыбыз да яңгырап торырга тиеш. Чын язучы милләтнең үткәнен, бүгенге хәлен, борчуларын, киләчәккә омтылышларын ачык күзалларга, төгәл белергә, аның әхлакый һәм сәяси кануннарын пропагандаларга тиеш. Чын язучы халык белән бергә булырга тиеш. Ул халык арасында булып кына калмыйча, аның белән даими рәвештә очрашып, аралашып, фикер алышып, аны дәртләндереп, шушы аралашулардан үзе рухи көч һәм иҗади ризык алып торырга тиеш.

Язучыларны артистлар белән тиңләргә тырышучылар бар. Артистларга халык алдына чыгып җырлаган өчен зур акчалар түлиләр, әдипләргә халык белән очрашулар вакытында бер тиен түләмиләр, диючеләр еш очрый. Мин үзем артистларны, җырчыларны язучылар белән тиңләмим. Аерма бик өстә ята. Артистлар, җырчылар шул ук язучылар иҗат иткән текстлар белән эш итә ләса! Артист халыкның күңелен күрә, аның күңел ихтыяҗын үти. Сәхнәдә роль башкара. Образга керә, уйный. Шуның өчен акча ала. Язучы, әдип халык алдына үзе булып, фикер иясе, әйдаман, хәтта рухани булып чыга, ул һич кенә дә уйнамый, халык анннан ихлас хис-тойгы, егәрле фикер, ахыр килеп, милли идеягә тиң сүз, образ көтә… Мин үз язмышыма төшкән миссияне шулай аңлап яшим.

3

– «Язучы шулай булырга тиеш», «язучының бурычы шул» кебегрәк сүзләр еш яңгырый. Ә менә «язучының хәле ничек?» дигәне бик ишетелми. Язучы бүген нинди хәлдә?

– Татар язучысының бүгенге хәле ярыйсы гына, дип уйлыйм. 90нчы елларда каләмдәшләребез тормышында күзәтелгән аянычлы хәлләр юк инде.

Бүген Татарстан Язучылар берлегенең, Мәдәният министрлыгының, республика җитәкчелегенең язучыларга игътибары юк дип әйтә алмыйбыз. Берлектәге 350ләп язучының һәрберсе күз карамагында, ветераннарга барып торыла, азмы-күпме өстәмә пенсия түләнә, матди ярдәм күрсәтелә, бәйрәмнәрдә төрле чаралар оештырыла, социаль пакетлар бирелә. Бераз гына льготалы путевкалар да бар хәтта. Халык әдипләренә өстәмә пособие билгеләнгән. Юбилей кичәләре үткәрү өчен тиешле акчалар каралган. Язучыларга вакытлы матбугат басмалары яздыру буенча да махсус кампанияләр оештырыла. Ел саен биреп барыла торган әдәби премияләр, стипендияләр дә берничә дистәгә җыела. Әлбәттә, болар гына аз, әмма Россиядәге башка төбәкләрдә боларның берсе дә юк. Мин моны төгәл белеп әйтәм.

Язучының бүгенге хәлен республикадагы гонорар сәясәтеннән башка карап булмыйдыр. Бу мәсьәләне хәл итеп бетерәсе бар. Дөрес, хөкүмәтнең махсус карары нигезендә, соңгы елларда нәшриятларда, әдәби басмаларда гонорарларны күпмедер арттырурга ирештек. Ходайга шөкер һәм җитәкчеләребезгә рәхмәт – нинди генә авыр елларда да Татарстан китап нәшриятында басыла торган китапларыбызның саны кимемәде. Туган нәшриятыбызның фидакарьләрчә алып барган эшчәнлеген әле бәяләп тә бетерә алганыбыз юк. Уртача өч-дүрт ел саен һәр язучы үзенең яңа китабын бастырып тора, димәк, гонорар ала, димәк, тормышын яхшырта.

Әйтүемчә, бу эш дәвам итә. Шушы юнәлештә республика җитәкчеләренең махсус «поручение»ләре бар. Гонорар ставкаларын дәүләт күләмендә җайга салып, тотрыклы итә алсак, китап бастыручы, газета-журналларда катнашучы әдипләребезнең хәле бермә-бер яхшырачак. Амин, шулай булсын!

4

– Язучы хезмәтенә рәсми статус бирүгә ничек карыйсыз, аны нинди юллар белән җайга салып була?

– Язучы хезмәтенә рәсми статус бирүне иҗат кешесен ниндидер кыса-рамкаларга көчләп кертү дип аңлыйм. Рәсми статус устав белән бәйле, ә уставны үтәргә туры киләчәк. Минемчә, язучының «статусы» ике төрле генә була ала: йә ул профессионал, йә ул һәвәскәр. Профессиональлек дәрәҗәсен билгели торган фактор да бар. Ул – Татарстан Язучылар берлегенә әгъзасы булу. Әмма бу да абсолют хакыйкать була алмый. Язучының дәрәҗәсен, талантын, бөеклеген, шул ук статусын бары тик халык (укучы) һәм вакыт кына билгели аладыр.

«Әдәби иҗат»ны башка һөнәрләргә тиңләп, язучылык статусын рәсми рәвештә кабул ителгән «профессияләр реестры» аша билгеләү хакында сорыйсыңдыр, бәлки? Әйтик, язучы үз өендә иҗат итеп ята, ә хөкүмәт аңа эш хакы түли… Мин үзем шактый хыялый кеше, әмма бу хәлне һич кенә дә күз алдына китерә алмыйм.

Ә менә иҗат кешесенә социаль пособие биреп баруны мөмкин эш дип саныйм. Әйтик, Германиядәге кебек. Анда һәр иҗат кешесенә, әгәр ул үзенең иҗат әһеле икәнен дәлилли алса, 700 евро чамасы пособие биреп барыла. Бу пособие анда «Германия халкының культурасын, сәнгатен, эстетик зәвыгын үстергән өчен» дигәнрәк исем астында мәгълүм.

5

– «Хәзерге заман укучысы» дигәнрәк сүзне бик еш кулланалар. Бу төшенчәне сез ничек кузаллыйсыз? Кем ул бүгенге заман укучысы, нинди ул? Гомумән, укучылар да заманга карап үзгәрәме, аерыламы?

– Әйе, андый төшенчә бар. Андый укучы бар. Хәзерге заман укучысы элеккеге дәверләр укучысыннан, хәтта бик үк ерак булмаган 80-90нчы еллар укучысыннан да аерыла. Ул иң элек «компьютер фикерләве»нә ия. Компьютер – аның иң якын дусты, киңәшчесе, ярдәмчесе. Ул компьютерда (интернетта), дөресме-түгелме, һәр сорауга җавап таба. Җаны ни сорый – шуны табып укый. Аның дөньяга карашы киң, әмма зәвыгы тар, шактый зәгыйфь. Монысы информациянең гадәттән тыш күп һәм төрле булуыннан киләдер. Бүгенге укучы озын әсәрләрне укый алмый, аның маңгай һәм зиһен күзләре кыска, җыйнак текстларга күнеккән, катлы-катлы сурәтләр, образлар да аны тиз ялыктыра, фәлсәфи фикер-уйлануларны, лирик чигенешләрне бөтенләй үк кире какмаса да, аларның төгәл һәм аңлаешлы булуын ярата. Бик кискен композицион борылмалар, тиз сөйләшле диалоглар, җете образлар, гыйбрәтле хәлләр, аянычлы язмышлар яки ачык, аңлаешлы юмор, көлкеле ситуация аны берникадәр тотып тора. Ул кулына алган әсәрне бер утыруда укып чыгарга тиеш. Аерылса, бик сирәк кабат кайтып укый.

Әлбәттә инде, бу калып-стереотипка туры килмәгәннәр дә бар. Һәр заманның үз укучысы булган кебек, барлык заман әдәбиятларын да бердәй йотлыгып укучы, үз итүче һәм күңеленә алучы укучылар да бар. Алар – чын укучылар, аларны «әдәбият сөючеләр» дип йөртәләр. Минем әнкәй шундый кеше. Мин үзем дә шундый кеше. Бу хакта төгәл әйтә алам.

6

– Язучының иҗади үсешендә әдәби тәнкыйтьнең роле бар дип уйлыйсызмы? Әдәби тәнкыйть бүген нинди хәлдә һәм аның үсеше өчен нәрсәләр эшләргә мөмкин?

– Язучының иҗади эволюциясенә әдәби тәнкыйтьнең турыдан-туры тәэсире бар. Әдәби тәнкыйть – тәнкыйть кенә түгел бит ул. Ул хәтта бәя генә дә түгел. Ул иң элек әдипнең иҗатын (әсәрен) анализлап, сүтеп-җыеп, укучыга, әдәби җәмәгатьчелеккә, хәтта язучының үзенә аңлатып бирүгә, бу иҗатның (әсәрнең) үзенчәлеген билгеләүгә корылган булырга тиеш. Бүгенге тәнкыйтьнең нәкъ менә шул функциясе юкка чыкты, «әйбәт» яисә «начар» дип кенә язылган реплика-мәкаләләр яисә купшы фәнни сүзләргә төрелгән академик язмалар белән генә укучының игътибарын теге яки бу әсәргә (иҗатка) җәлеп итеп булмый, минемчә. Әйтүемчә, әдипнең иҗат эволюциясен, аның җан диалектикасын, иҗади язмыш интригасын бары тик аналитик шәрехләмә, поэтик тикшеренүләр ярдәмендә, композицион метаморфозалар (әверелешләр) аша, образлар үстерелешен өйрәнеп кенә күзаллап буладыр.

Бүгенге әдәби тәнкыйтькә яңа импульс бирү өчен нәрсә эшләргә кирәк? Иң элек яңа буын филологик кадрлар әзерләргә кирәк. Яңа буын иҗатчылар килә тора, ә аларга бәя бирә алырдай фикер ияләре күренми. Җанлы әдәби процессның төп тенденцияләрен билгели алырдай, заманча фикерле торган, дөнья әдәбияты казанышлары белән таныш, үзе дә иҗатта көчен сынаучы егетләр-кызлар тәрбияләргә кирәк безгә. Филологик вузлар гына түгел, иҗат берлекләре дә, вакытлы матбугат та, китап нәшриятлары да, электрон ресурслар да тәнкыйди-аналитик фикергә йөз белән борылырга тиеш бүген.

7

– Әсәрләрне тарату, китап сәүдәсе. Бу өлкәдә сез нәрсәләр үзгәрүен теләр идегез? Әллә ул шушы хәлендә дә бик уңышлы эшлиме?

– Бүгенге көндә төп нәшриятыбыз булган Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан китапларның 85 проценты китапханәләргә, мәдәният учакларына, милли автономияләргә, Россия төбәкләрендә яшәүче милләттәшләребезгә бушлай җибәрелеп барыла. Татарстан хөкүмәтенең махсус карары белән эшләнә торган бу эш бүгенге көндә үзенең нәтиҗәләрен күрсәтте. Без укучыларыбызны саклап калдык. Ничекме?

Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан һәр китапны укучыларыбызга китапханәләр аша ирештереп бардык. Кибетләрнең ябылуы, китапларның кыйммәтләнүе аркасында укучы китаптан читләшә башлаган бер мәлдә, китапханәләрнең барлыгын искә төшердек, аларга, яңа китаплар белән бергә, яңа сулыш өрдек. Укучыларны кабат китапларга ияләштердек. Интернеттан әдәбият эзләп булашкан бер буыннан соң яңа буын укучылар кабат китапка (аның басма һәм электрон вариантлары да күз уңында тотыла) әйләнеп кайта башладылар, бу фактны социологик тикшеренүләр дә расլый. Бу хәл көтелмәгәнчә әйбәт килеп чыкты. Нәшриятлар, милли китапханәләр басма китапларның электрон вариантлары, параллель рәвештә, үзләренең сайтларына куела башладылар. Экранда китапның тышын күргән, аның мониторда җем-җем килеп торган текстын укып караган милләттәшләребез, тансыклап, шул китапларны үзләрендә булдырыр өчен, китап кибетләренә чыгып киттеләр, күпләр, сатып алырга мөмкинлекләре булмагач, кулга булса да тотып карарга теләп, китапханәләргә юл алды.

Сүз дә юк, бездә китап сәүдәсе дә җайга салынырга тиеш. Әлегә ул бик зәгыйфь хәлдә генә гомер кичерә. Интернет-кибетләр дә халыкка ныклап барып җитә алмады. Күрәсең, сәүдә юнәлешен җайга салу өчен, киләчәктә махсус Дәүләт программасы кабул итәргә кирәктер. Бүгенге укучы кесәсе өчен китаплар бик кыйммәт. Дәүләт программасының төп максаты шушы кыйммәтчелекне бетерү булырдыр, мөгаен. Бу эш, минемчә, полиграфиядәге монополияләрне җимерү, китап бастыруда конкурентлыкка шартлар тудыру белән бәйле булачак.

8

– Язучы һәрвакыт укучылары белән аралашырга тиеш дигән сүз бар. Сез моңа ничек карыйсыз? Укучыларыгыз белән аралашып торасызмы? Аның өчен нинди мөмкинлекләрне файдаланырга мөмкин?

– Укучыларым белән даими аралашып торам. Бу юлда нинди мөмкинлек килеп чыга – ике дә уйламыйча файдаланып калырга тырышам. Моңа кадәр балалар бакчаларыннан, мәктәпләрдән, авыл-салалардан, оешмалардан, бәйрәм-җыеннардан килгән бер генә чакыруны да кире каккамым булмады. Бик актив елларда елга 150шәр очрашу җыела иде. Бу күрсәткечкә миңа кадәр бары тик берничә әдип кенә ирешә алган иде. Шуңадырмы, аларны халык чынлап та теленнән төшермичә, яратып яшәде. Менә алар: Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Резеда Вәлиева. Роберт Миңнуллин белән Разил Вәлиев тә халык арасыннан кайтып керми. Туфан абый Миңнуллин да гел халык белән булды. Яшьрәкләрдән Ләбиб Лерон, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Марат Закир, Илсөяр Иксановалар буыны да гел очрашуларда. Алар шагыйрьнең чын миссиясен аңлап яшиләр. Мин аларга да сокланам, үрнәк алам.

9

– Яхшырак язу өчен язучыга нинди шартлар тудырырга кирәк, дип уйлыйсыз?

– Чын әдип нинди генә шартларда да иҗат итә ала, дип уйлыйм. Муса Җәлилнең фашист тоткынлыгында шартлары булганмы? Гомере буе фатирсыз яшәгән Мөдәррис Әгъләмнең яшәү шартлары яхшы булганмы? Ике-өч катлы коттеджларга күчеп яши башлаган язучыларның иҗатлары кинәт кенә сүнеп калган очракларны да беләбез. Димәк, иҗат өчен яшәү шартлары төп күрсәткеч түгел. Әмма язучының иҗаты гына түгел, аның гаиләсе, балалары, якыннары, дуслары бар бит әле. Аның әле вәкаре (достоинствосы) булырга тиеш. Димәк, һич югы, яшәр урыны, йорт-җире, кунакка килгән әти-әнисен, туганнарын, дусларын, каләмдәшләрен, шул ук укучыларын каршы алырга тиеш урыны булырга тиеш аның. Минемчә, тормышы, эше, иҗаты зур акчалар белән бәйле булмаган язучыга фатир алырга яисә җир биләмәсе юнәтергә хөкүмәттән берникадәр социаль һәм акчалата ярдәм күрсәтелергә тиеш. Мохтаҗ язучыларга махсус закон кысаларында тотрыклы пособие булдырылса, бу эш иҗат кешесенең тормыш хәлен кайгыртуда тагын бер адым булыр иде.

Бүген Татарстан Язучылар берлегендә пенсионер язучыларга берникадәр пенсия каралган. Инде шул яклап өлкән каләмдәшләребезгә игътибарны юнәлтәбез икән, Татарстан хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән бу акчалата ярдәм (өстәмә пенсия) һич югы 3 мең чамасы булырга тиеш, дип уйлыйм.

Бер уңайдан, депутатлар колагына да әйтеп үтәргә кирәк: «Иҗат берлекләре турында»гы законны кайчан кабул итәсез инде? Бу законның проектында язучының, сәнгать кешесенең хәлен яхшырту буенча бөтен тиешле гамәлләр дә каралган иде ләса?!

10

– Соңгы вакытта нинди әсәр язасыз? Бу әсәр нәрсә хакында? Аны кайдан табып укырга мөмкин (булачак)?

– Соңгы вакытта ике әсәр белән хыялланып яшим, икесе дә бик авыр бара, икесе дә фаҗигале, әмма мавыктыргыч язмышлар турында. Беренче роман хакында матбугатта игълан иткән идем инде, ул мәшһүр татар-башкорт шагыйре Шәехзадә Бабич турында, икенче әсәрем шайтан коткысына бирелгән татар егете хакында. Табадан гына төшкән берничә хикәям дә бар. Аларын якын арада татар вакытлы матбугатында табып укырга мөмкин булачак.

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ

«Өмет белән яшәү җайлырак...»

Тукай, Бабич

Хак сүз икән: үз пәйгамбәреңне
Чит җирләргә китеп эзләмә.
Авыр чакта күңел Тукайларга,
Бабичларга барып тезләнә.

Изге дога онытылган чакта,
Җимерелгән чакта кыйблалар,
Күңелдәге хисләр шушы изге
Исемнәргә кайтып егылалар.

Менә сүнәм-сүнәм дип торганда
Соңгы тамчы өмет чаткысы,
Тарихымда кояш булып калка
Тукай нуры, Бабич яктысы!

Бу дөньяда җан кайгысымыни?!
Баш кайгысы, байлык кайгысы!
Каткан бәгырьләргә
беркеп кайта
Тукай хисе, Бабич тойгысы!

Бер югалтсаң инде үз рухыңны,
Бер югалтсаң инде үз телеңне,
Бер югалтсаң инде үз илеңне,
Хәтеркәең һаман эзләнер...

Тукай рухы, Бабич рухы беркөн
Алларыңа кайтып тезләнер!

Бала чакта

Бала чакта, карда аунап туйгач,
Өйгә чабып керә идем дә...
Әнкәемнән кар кактыра идем,
Күл җәелә иде идәндә...

Хәзер дә бер, их, кайтасы иде,
Әнә мамык түши юлларны.
Әнкәемнән кактырасы иде
Чәчләремә кунган ак карны...

Миңеште

Якташым Наҗар Нәҗмигә

Нинди җир бу? Нинди дөнья? —
Шунда ук тылсым йога.
Сулыш булып җанга иңә
Серле-илаһи дога.

Кайчакта җил белән оча
Бу җирдә тарих көле.
Бер җан булып бәргәләнә
Башкорт һәм татар теле.

Тауларында усак үсә,
Һәр йорт каршында — миләш;
Малайлар Урал исемле,
Һәр кунак кызы — кәләш!

Агачлар сөйләшә монда,
Куаклар: «Шыбыр-шыбыр!..»
Һәр үлән – мандолин кылы,
Һәр яфрак асты – шигырь!

Баланның ачы суы да
Татлы булып тоела.
Шундый җир бу: моңсыз яшәү,
Җырсыз яшәү — тыела!

Сизәм: кайсыдыр гомердә
Монда туган булганмын...
Шулкадәр дә җанга якын
Моңлы көе кылганның...

Сизәм: мин – шушы туфракның
Иң гади, нәни кәсе.
Тоям: мин – Наҗар Нәҗминең
Иң төпчек энекәше...

Әткәй-әнкәй миңа ат бирде

Әткәй-әнкәй миңа ат бирде,
«Күзең төшкән якка чап, – диде.
– Күңелеңдә нинди хыяллар бар?
Дөнья гизеп йөрер чак», – диде.

Әткәй-әнкәй биргән бу атны
Дөнья бәйгесендә чаптырдым.
Офыклардан офыкларга йөреп,
Шул ат белән
таңнар аттырдым.

Әткәй-әнкәй биргән бу атка
Атландырдым бөтен дус-ишне.
Җилдәй җилгән чакта бар дөнья
Карап торды безнең очышны.

Әткәй-әнкәй биргән ат өчен
Җан өлеше сорый һәр бәндә.
Ачы кайгы, сары сагышта
Исем-атым килә ярдәмгә.

Әткәй-әнкәй биргән ат белән
Гомер кичү җиңел түгел лә...
Ләкин беләм: алда юл озын,
Өмет-хыял яши күңелдә...

...Мин аңладым хәзер, аңладым:
Гомер атым әл дә бер дигән...
Ә бит әткәй-әнкәй: «Бу атта
Безнең янга кайтып йөр», – дигән.

Күтеп яшим

Киләчәктән нидер көтеп яшим,
Өмет белән яшәү җайлырак.
Артык үсенмим дә,
чөнки беләм –
Кояш ерак, хәтта Ай ерак...

Һәрбер аткан таңга
рәхмәт әйтәм,
Яңа туган һәр көн яктырак.
Күңелдәге хисләр самимирәк,
Һәм уйлаган уйлар яхшырак...

Дөнья – ымсындыргыч,
кичләр – изге,
Сине биргән кичләр бигрәк тә.
Күз карашың булып
туган өмет
Баш күтәреп йөри йөрәктә...

Сине күргән саен, җан ашкына,
Күзләремдә өмет яшьләрем.
Киләчәктән нидер көтеп яшим, –
Кабат кайтыр кебек яшьлегем.

vk.com

Ялыкмаслар кавеменнән

Кайбер җырчылар сәхнәгә шаулап килеп чыга да, бераз шау-гөр килеп алгач, тиз арада онытыла да башлый. Ә берәүләре, киресенчә, олы сәнгать ишегеннән тыйнак кына атлап керә дә, моң иленә булдыра алган кадәр үз өлешен кертергә тырышып, аңа гомер буе хезмәт итә. Шушы фидакарьлеге ахыр чиктә аңа абруй китерә һәм ул үз эшендә алыштыргысыз остага әйләнә.

Татарстанның халык артисты Шамил Әхмәтҗановның иҗат юлы шушы фидакярлекнең ачык мисалы булып тора. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә әйдәп баручы җырчы-солист буларак ул иң озак эшләүчеләрнең (35!) берсе булды.

Без Шамил белән Казан музыка училищесында укыган елларда ук танышып, гомер буе иҗади дуслыкта яшәдек. Шул елларда ук ул – җырчы, мин баянчы буларак, училищега якын гына булган радиокомитетка кереп җырлар яздыра идек. Шунысын да әйтергә кирәк, югары профессионаллардан торган худсовет без яздырган җырларны «яраксыз»га чыгармыйча, гел радио фондына кабул итә килде.

1967 елда Шамил училищены тәмамлап (ул миннән бер курска алда укыды), Татар дәүләт филармониясендә җыр-бию ансамблендә эшли башлады. Ә бер елдан соң мин дә, юллама белән, филармониягә эшкә килдем. Эстрада бүлегендә эшләргә ниятләгән идем, әмма анда баянчы урыны булмаганлыктан, миңа җыр-бию ансамблендә эшләп торырга тәкъдим иттеләр. Шулай итеп, Шамил белән без тагын бергә туры килдек. Мәгълүм ки, ансамбльнең концерт программасы күмәк чыгышлардан тора. Ә инде аерым (соло) җырлау ул бик зур мәртәбә санала һәм бу бәхет бик сирәк җырчыга эләгә. Шамил исә иҗат юлының буеннан-буена шушы бәхеткә тиенгән җырчы булды. Мин ансамбльдә эшләгәндә, концертның беренче бүлегендә – Шамил, ә икенчесендә Таһир Якупов җырлый торган иде. Гастрольләрнең берсендә гомердә дә онытылмаслык хәл булды. Сәхнәгә чыгар алдыннан гына Шамил: «Әйдә бүген "Урман"ны җырлыйбыз, соль мажорда уйна», – диде. Мин тональностьның дөрес түгеллеген сиздем, ләкин аңлашып торырга вакыт калмаган иде инде. Җырлый башлауга ук Шамил дә ялгышын аңлады аңлавын, ләкин соң иде инде. Ул, ялгыш, югары – тенор тавышлы җырчылар тональностен әйткән икән, ә Шамил – баритон. Башка берәү булса, шып туктап, түбәнрәк уйнавымны сорар иде. Ә Шамил тирләп чыкса чыкты – сер бирмәде. Җырны тәки башкарып чыкты! Бу аның тавышының киң диапозоны булуы һәм яхшы вокал мәктәбе үтүенә дәлил иде.

Ансамбльдә бер ел эшләгәч, мине эстрада бүлегенә, Илһам Шакиров җитәкчелегендәге концерт бригадасына күчерделәр. Шулай да Шамил белән иҗади элемтәләребез өзелмәде. Әйткәнемчә, ул бүгенгәчә дәвам итә. 2015 елда Мәдәният министрлыгы безне Кырымга, Симферополь белән Севастополь шәһәрләрендә узачак Сабан туйларында катнашып чыгыш ясарга җибәрде. Анда безнең белән, рәсми вәкил буларак, Дәүләт Советы депутаты Рафил Ногманов та бар иде. Симферополь Сабан туе шәһәр читендәге паркта үтте. Севастопольнеке шәһәрдән ике-өч чакрымдагы урында – агачлар белән капланган таулар арасындагы бер аланлыкта уза икән. Анда электр уты да узмаган, димәк, көчәйткеч аппаратура да, микрофон да юк дигән сүз. Шунда мин, 74ен тутырган Шамил агабыз монда ничек кенә җырлар икән инде, дип уйлап куйдым. «Карт алаша буразна бозмый», дип юкка гына әйтмәгәннәр. Шамилебез бер дә каушап калмады – табигый тавышы белән бөтен аланны яңгыратып, биш-алты җыр башкарды. Тамашачы аннан соң да тиз генә мәйданнан җибәрмәде әле үзен. Көчле алкышлар белән, кабат-кабат җырлатты.

Хәбир Иштирәков җитәкчелегендәге Республика ветераннар советы 2012 елдан башлап үзешчән сәнгатькә катнашучы ветераннарның «Балкыш» дип аталган фестиваль-конкурсын үткәреп килә. Шамил шушы конкурсның рәисе вазифасын башкара. Мин дә шунда жюри әгъзасы. Фестиваль барышында җырчылар аңа төрле сораулар белән мөрәҗәгать итә. Шамил, әлбәттә инде, иренми, бик теләп киңәшләрен бирә. «Ул менә шулайрак башкарылырга тиеш», – дип җырлап та җибәргәли. Җыеп кына әйткәндә, ялыкмаслар кавеменнән безнең Шамил. Әле бүген дә иҗат белән яши, халыкка хезмәт итә ул.

Рамил КУРАМШИН,
Татарстанның
халык артисты.

«Без егылсак...»

Олыгая барган саен, күңел дәфтәрен ешрак актарасың, хәтер сәхифәләрен яңартасың, шуларга таянып, алга таба гомер сөрәсең. Ә хатирәләр – бихисап.

Әле шушы көннәрдә генә эш бүлмәмә 76 яшен тутырып килүче Шамил абый Әхмәтҗанов килеп керде. Балачактан ук җырларын, моңын күңелемә сеңдергән Шамил абый. Ул үзе Арча районының Курса-Почмак авылы егете, минем якташым, халкыбызның яраткан җырчысы, Татарстанның халык артисты. Бу инде минем үз гомеремдә Шамил абыйга карап икенче тапкыр соклануым. Беренчесе моннан күп еллар элек, Арча электричкасында Шамил абый белән ике өлкән абыем (Шамил Әхмәтҗановның чордашлары Марсель һәм Габделхәй) сөйләшеп торганда булды. Аның чит илләргә булган гастрольләре, Татарстан җыр һәм бию ансамбленең ничек алкышларга күмелүе турында мавыктыргыч итеп сөйләве әле дә күз алдымда. Яшүсмер малайның «чын артист» белән якыннан танышуы, аңа һәм сәнгать дөньясына соклану иде бу! Бүгенге очрашуыбыздан соң мине янәдән шул хисләр биләп алды.

Ул елларны татар радиосы тапшыруларын көтеп алабыз, чөнки авылларда күңел азыгы алырлык башка бер генә нәрсә дә юк. Нинди генә яңа җыр, спектакльләрдән өзекләр яңгырамасын, яңа җырчы җырламасын, барысы да нәзберек бала күңеленә сеңә. Нәкъ менә шул җырчы тавышына охшатып җырлыйсы, аның бөтен нечкәлекләренә, бормаларына, аһәңенә барып җитәсе килә. Миндә дә булды бу халәт. Ә җырчылар ул вакытта күп түгел, әмма аларның һәрберсе синең күңелеңдә үз урынын ала иде. Шамил Әхмәтҗановка охшатып җырларга тырышу, ул җырлаган җырларны өйрәнү теләге бик зур иде. Күпчелек ул халык җырларын, мәшһүр композиторларыбыз язган җырларны башкара. Менә хәзер үз үрем һәм тәҗрибәмнән чыгып, мин берникадәр остазым булган Шамил абыйга татар җыр сәнгатендә үз аһәңен булдырганы, бу юнәлештә дистәләгән еллар армый-талмый эшләп килүе өчен олуг рәхмәтемне җиткерәсем килә. Ә ул башкарган җырлар бихисап: «Арча», «Бирәзә авылы көе», «Күгәрчен гөрлидер», «Зәңгәр күлмәк», «Өзелгән өмет», «Туган җиремә», «Туган авыл», «Бик сагынган чаклар була сине», «Казан кичләре», «Сорнай моңы», «Тамчылар тамар чаклар»...

Торгынлык заманнарында ук, дөньякүләм гастрольләрдә татар җырын яңгыратып, чит ил тамашачысы күңеленә татар халкына соклану уяткан, алкышларга күмелгән җырчыбыз ул Шамил абый. Ул чорда Татар җыр һәм бию ансамбле җырчылары Шамил Әхмәтҗанов, Таһир Якупов, Ания Туишева, Мөҗип Садыйков, Нәфисә Васылова тамашачы алдында абруй казанган сәнгатьпәрвәрләр иде. Алар – татар җыр сәнгатенең йөзек кашлары, чын безнеңчә милли аһәңле җырчылар. Һәм алар арасында мин, ассызыклап, Шамил Әхмәтҗановны әйтер идем. Ул бүген дә 1967 елда башлаган иҗат юлын шушы данлы коллективта дәвам итеп, бар туплаган тәҗрибәсен яшь җырчыларга тапшыра. Шамил абыйга исәнлек-саулык теләп, безнең арада әле бик күп еллар иҗат итәргә насыйп булсын дигән теләктә, Мөдәррис Әгъләмовның шигъри юлларына тукталам:

... Без егылсак... Әнә шул хакта син
Уйла, эшлә, яшә!
Янәшәңдә кем юк димә,
Яшьләр янәшә.

Айдар ФӘЙЗРАХМАНОВ,
Россиянең атказанган,
Татарстанның халык артисты, профессор,
Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт
филармониясенең сәнгать җитәкчесе.



Нияз Бишбалта төзеде

Чайнворд

«Уку йортлары, уку-укыту»

1. Беренчедән башлап саналган уку елларының берсендә укыган укучылар төркеме.
2. Букча.
3. Югары уку йортларында гыйльми яки фәнни-педагогик кадрлар әзерләү системасы.
4. Фән һәм сәнгатьне үстерү бурычы йөкләтелгән югары дәүләт учреждениесе.
5. Нинди дә булса чыганактан чыккан нурлар (караңгыдан котылып, китап уку өчен кирәк).
6. Югары музыка уку йорты.
7. Сыйныфташыңа булышлык күрсәтү.
8. Гомуми белем һәм тәрбия бирә торган уку йорты.
9. Утыргычы беркетеп ясалган, укучылар өчен махсус авыш өсле өстәл.
10. Укучыларның туклану урыны.
11. Укучыларга кирәкле булган әдәпкә өндәгән әсәрләр.
12. Махсус урта белем бирә торган уку йорты.
13. Мөселманнарда урта һәм югары уку йорты.
14. Укытучы югары …лы булырга тиеш.
15. Урта һәм югары уку йорты арасындагы махсус уку йорты.
16. Укыганда тырыш булу.
17. Кыска вакытлы уку йорты.
18. Югары уку йортларында уку елының бер яртысы.
19. Югары уку йорты башлыгы, җитәкчесе.

Җаваплар.
1.Класс 2.Сумка 3.Аспирантура 4.Академия 5.Яктылык 6.Консерватория 7.Ярдәм 8.Мәктәп 9.Парта 10.Ашханә 11.Әдәбият 12.Техникум 13.Мәдрәсә 14.Әхлак 15.Көллият 16.Тырышлык 17.Курс 18.Семестр 19.Ректор.

РОСКОМНАДЗОР КИСӘТӘ!

«Шәхси мәгълүматлар турында»гы Федераль закон нигезендә, шәхси мәгълүматлар эшкәртүне башкарып та, Шәхси мәгълүматларны эшкәртү Реестрында теркәлмәгән операторлар ТР буенча Роскомнадзор идарәсенә **белдерү хаты җибәрергә тиеш,** ә инде **2015 елның 1 сентябреннән,** «Россия Федерациясенең мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләрендә шәхси мәгълүматларны эшкәртү тәртибенең төгәллеген тикшерү өлкәсендә кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турындагы» 242-ФЗ санлы Федераль законның (21.07.2014 кабул ителгән) 2 маддәсе нигезендә, өстәмә рәвештә, РФ гражданнарының шәхси мәгълүматлары саклана торган мәгълүмат базасы урнашкан урынны күрсәтергә кирәк булачак. (Казан, Гарифҗанов урамы, 28а йорт, 420138, а/я 25.) Роскомнадзор шулай ук реестрда 2011 елның 1 июленә кадәр теркәлгән операторлар өчен оператор турындагы мәгълүматларга **үзгәрешләр кертү турындагы документ** формасының үзгәртелүе (гадиләштерелүе) турында хәбәр итә. Шул ук вакытта операторларга 242-ФЗ санлы Федераль законның (21.07.2014 кабул ителгән) 2 маддәсе таләбе буенча, **2015 елның 1 сентябреннән,** РФ гражданнарының шәхси мәгълүматлары саклана торган мәгълүмат базасы урнашкан урын хакында мәгълүмати хат юлларга кирәк булачак. Тулырак мәгълүмат – **http://16.rkn.gov.ru/** һәм **http://pd.rkn.gov.ru/** сайтларында.

СПОРТ

Чаңгычыларга – бер миллион

Казанның Юдино бистәсендәге «Локомотив» чаңгы базасында 4 февральдә 10.00 сәгатьтә «Казан чаңгы марафоны» була.

Марафон үткәрелә башлаганга быел – 50 ел. Татарстаннан, Россиянең башка шәһәрләреннән һәм Казахстан белән Чехиядән барлыгы 670 чаңгычы юбилей узышларда катнашырга язылган.

– 500 спортчы 50 чакрым араны җиңәргә исәпли. 100 кеше 25 чакрымга чыга, ә калганнары 5 чакрым арада узышачак. Алдынгы урыннарны яулаучыларга приз фонды – бер миллион сум, – диде шәһәр Башкарма комитетының физкультура һәм спорт комитеты рәисе Светлана Вострикова.

Рәдиф КАРАГАЙ.

Җыр кирәк күңелгә

Куплар, Татарстан эчке эшләр министрлыгы хокук саклау белән генә шөгыльләнә, дип уйлыйдыр. Ә бит алар шигъри, әдәби-музыкаль кичәләр уздырырга да вакыт таба.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, оештыручыларның берсе Ольга Левадная фикеренчә, мондый чаралар бик мәгънәле, күңелле уза. Әле менә күптән түгел генә Татарстанның атказанган артисты Галина Петрусеваның юбилей кичәсен матур итеп оештырганнар иде. Шунысы да үзенчәлекле: кичәдә рус җырчысы татар әсәрләрен дә башкарды. Россиянең халык артисты Эмиль Җәлаләтдинов белән ул Ләбиб Айтуганов сүзләре, Рөстәм Яхин көенә язылган «Ышанма» җырын башкардылар. Баксаң, Галина ханым Татар дәүләт филармониясенең әдәби-музыкаль лекториясендә эшләгәндә, нәфис тел остасы Айрат Арслановтан махсус рәвештә татар теле дәресләре алган булган икән. Кичәне музыка белгече, филология фәннәре кандидаты Лилия Сафиуллина җырлар, биюләр, нәфис сүз белән үреп алып барды. Хокук саклаучылар күңелләргә үтеп керерлек менә шундый кичә оештырдылар. Җыр-моң һәркайда да кирәк шул.

Равилә МӨБАРӘКШИНА,
Казан.

АФИША
6 – 12 ФЕВРАЛЬ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

7 февраль «Җилкәнсезләр» (К.Тинчурин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

8 февраль «Исәнме, улым!» (Б.Абдураззоков)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 300-350 сум

8 февраль «Сөясеңме, сөймисеңме...» (Ф. Бүләков)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

9 февраль «Көтәм сине...» (И.Зәйниев)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

10 февраль «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

11 февраль «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев)
Башлана: 12.00
Билет бәясе: 150-1000 сум

11 февраль «Галиябану» (М.Фәйзи)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

12 февраль «Кечтүкле уен» (И.Зәйниев)
Башлана: 12.00
Билет бәясе: 120-500 сум

12 февраль «Гөргөри кияүләре» (Т. Миңнуллин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

7 февраль «Туй алдыннан» (Х.Вахит)
Башлана: 18.30

8 февраль «Кияүләр» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.30

9 февраль «Әллә язмыш, әллә ялгыш» (Н.Нестерова, Р.Гарипова инсц.)
Башлана: 18.30

10 февраль «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.30

11 февраль «Ефәк баулы былбыл кош» (А.Гыйләҗев)
Башлана: 17.00

12 февраль «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов)
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 250-600 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

8 февраль «Бүре җиләге» (Р.Зәйдулла)
Башлана: 11.00

9 февраль «Айболит» (К.Чуковский, Н.Егорова инсц.)
Башлана: 11.00, 13.00

10 февраль «Аленький цветочек» (С.Т.Аксаков)
Башлана: 11.00, 13.00

11 февраль «Муха-цокотуха» (К.Чуковский)
Башлана: 11.00, 13.00

11 февраль «Не хочу, не буду»
Башлана: 11.00

11 февраль «Ханума» (К.Чуковский)
Башлана: 18.00

12 февраль «И, кызык Шүрәле!..» (Г.Зәйнашева)
Башлана: 11.00

12 февраль «Щелкунчик» (Э.Т.А.Гофман)
Башлана: 13.00, 15.00
Билет бәясе: 200-300 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

7 февраль Зур концерт
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 300-800 сум

7 февраль Марсель Вәгыйзов
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 400-1200 сум

11 февраль Зөфәр Билалов белән Зәйнәб Фәрхетдинова концерты
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 500-2000 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Фотохәбәрчеләр Илдар Мөхәммәтҗанов белән Шамил Абдюшевның «Чор һәм шәхес» дип аталган фотокүргәзмәсе эшли.
Керү ирекле (эш көннәрендә)

Зәйнәб белән Зөфәр Трампның туган ягына ник бармаган?

– Дөньяда Американың «яңа гына табадан төшкән» 70 яшьлек президенты Дональд Трампны сөйләүдән туктамыйлар. Шушы «мода»дан калышырга теләмичә, мин дә Америка рухы белән сугарылган сорау бирим әле: сезне дә кайчандыр АКШка чакырган булганнар, әмма ни сәбәпледер, баш тарткансыз...

Зәйнәб:

– Дөресен әйткәндә, мин ябык урыннарда ике сәгатьтән артык була алмыйм. Шуңа да очкычта ерак араларга йөрергә куркам. Әгәр сөйләшенгән икән, бармый хәлең юк, андый вакытта үземне кулга алам. Мәскәү, Уфа кебек якын арага түзәбез инде.

Зөфәр:

– Поездда йөрергә күбрәк яратабыз. Анда уңайлырак та... Элек шулерлар, караклар поездда йөреп, пассажирларның акчаларын, әйберләрен урлый иде. Бәхеткә, бу үткәндә калды. Хәзер хокук саклау органнары яхшырак эшли, тәртип бозучылар өчен зур штрафлар да каралган бит.

Поездда ашау – үзенә бер рәхәтлек. Аны авылда көтү көткәндә йомырканы ипи, суган белән ашагандагы күңелле мизгелләр белән генә чагыштырып була торгандыр. Тик яшь бара-бара, сулаган һавадан да «кабарасың» бит, шуңа, поездда барганда, өйдә пешергән ризыкларны алмаска тырышабыз. Чәй белән кечкенә бутербродтан авыз итсәң, шул җитә. Ачлы-туклы йөрсәң генә ябыга башлыйсың.

Зәйнәб:

– Алтынчы класста чөгендер басуында эшләгәндә йомырка белән ипи ашап утырган чаклар искә төште әле. Элек юл буенда, станцияләрдә кафелар юк иде. Бригада белән гастрольләргә ерак арага барганда, үзебез белән һәрвакыт өч көнгә җитәрлек ризык ала идек.

– Лотереяда бәхетегезне сынаганыгыз бармы?

Зөфәр:

– Казанның Ботаническая урамындагы тулай торакта яшәгәндә, «36дан 5не» дигән спортлото уйный идем. Вак-төяк отышларның чыкканы булды. Бәләкәй вакытта авылда көндәлек кирәк-ярак уйната торган ике тираж бар иде. Берсендә әти-әнием 96 сумлык (ә ул вакытта бу зур акча) патефон отып, бүләкне акчалата алды.

1989 елда бер җырчы мине үзе белән Ташкент шәһәренә алып барды. Колак чите белән бер әйберне ишетеп калдым: янәсе, җуликлар урамда акча янчыгын махсус ташлап калдыра. Аны алсаң, бераү каршыңа йөгереп чыга да: «Анда акчам күбрәк иде», – дип тавыш чыгара, булмаган акчаны синнән таптыра башлый. Безгә дә Ташкентта көпә-көндез акча янчыгы очрады, егетләргә тимәскә куштым. Арттан бераү килеп: «Ник алмадыгыз?» – дип сорады.

Зәйнәб белән бер әйбергә игътибар иткәнебез бар: җиңел юл белән кергән акча, бүләк бик тиз чыгып китә. Үз тырышлыгыбыз һәм хезмәтебез белән тапкан акчаның гына бәрәкәте була.

– Бүгенге көндә ничек баеп була икән?

Зөфәр:

– Безнең илдә мөмкинлекләр күп. Акча аяк астында ята, диләр бит. Үзебезнең Казанны гына алыйк. Урта Азия халыклары монда килеп рестораннар, кибетләр ача, базарлар тота. Ә безнең халык ни өчен бу эшне булдыра алмый? Бәлкем, ялкаулык көчледер?

Балаларыбыз, безгә караганда, бар яктан да уңышлырак булырга тиеш, дип әйтә киләбез Зәйнәб белән. Олы улыбыз Булат үзен пицца таратучы, машина юучы булырак та сынап карады, тавыш аппаратурасы белән дә эш итә белә. Ир-ат никадәр күбрәк өлкәне белсә, шулкадәр яхшырак.

Зәйнәб:

– Кече улыбыз Фоат тугызынчы класста укый, бергәләп имтиханнарга әзерләнәбез әле.

– Ничек уйлыйсыз, гомер буе популяр булу мөмкинме?

Зөфәр:

– Юк, ул гомер буе бара алмый. Дөрес, халык безне бүген дә күрә, таный, урамда очратсалар, фотога төшәргә сорыйлар.

Яшь чакта Чаллыга бер баруда егермешәр концерт куя идек. Азнакайга кайтып, биш көндә унар концерт эшләгәнебез дә бар. Бу – татар эстрадасында рекорд дисәм, дөрес булыр, аны уздырган кеше юк әле.

Танылу ике төрле була. Беренчесе: 90нчы еллар башында җанатарларыбыз, ыжгырып килеп, безне тизрәк күрергә теләп, концерт залларының ишекләрен җимереп керә иде. Милиционерларның куркудан хәтта эш урыннарын ташлап киткән чаклары булды.Популярлыкның икенчесе хәзерге чорга туры килә – халык безне танып ала, мәхәббәтен белдерә, без дә аларга бар рәхмәтебезне җиткерәбез. Бернәрсә дә мәңгелек түгел, вакытлыча гына. Әмма шундый чорда да, кирәклегеңне белеп һәм белдереп, гаиләңне дә онытмыйча, милләткә аз гына файда эшләсәң дә, димәк, син дөрес юлда.

Линар ЗАКИРОВ.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.
ЧЫГАРЫЛЫШ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ – РАСИХА ГАБДЕЛБӘР кызы ИСМӘГЫЙЛОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1545. Гомуми тираж – 5719.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 672. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12,
факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы